Хезмәт батырлары

Язмамның геройлары депутатлар да, очучылар да, генераллар да, мәшһүр җырчылар да түгел, гап-гади хезмәт кешеләре – эшче династиясен дәвам итүчеләр. Гади, булдыклы, тырышлар. Шул ук вакытта бик тату, үрнәк гаилә дә. Гафуровлар-Ганиевларның заводтагы хезмәт стажлары – 267 ел!

6 БИТ

Көйсез яз

Яз башында без бераз көйсезгә әйләнәбез: тәнне хәлсезлек, йокы баса, нерв киеренкелеге арта, организм үзенә аерым бер төрле игътибар таләп итә. Табиблар моны тиешле матдәләр җитмәү, ягъни витаминнар кытлыгы белән аңлата. Алар әйтүенчә, мондый халәт гадәттә февральдә үк башлана һәм май ахырына кадәр дәвам итә. Март-апрель – аның иң югары ноктасы.

13 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 16.03.2017 | № 27 (5789)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

АВЫЛ АГАЕ

Гади авылның гап-гади бер абзые. Гомер буе туган авылында, ата-ана нигезендә яшәгән, иген иккән, ат җиккән, мал тоткан, балалар үстергән. Нинди уй-фикерләр белән яши икән ул бүген? Аның күңелендә моң-зармы, шатлык-куанычлармы? Авырмы бүген аңа яшәргә, җиңелме? Балтач районы Арбор авылыннан Фәләхетдин абзый Сәләхетдиновның сөйләгәннәрен газета укучыларыбызга ничек бар шулай тәкъдим итәбез.

4 БИТ

Зөлфия Хәлиуллина фотосы

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга 66 сум 99 тиен

3 айга 200 сум 97 тиен

6 айга 401 сум 94 тиен

Реклама

Ташламалы бәядән язылып кал!

Һәр айның 15 числосына кадәр язылсагыз, газета киләсе ай башыннан киләчәк.

Синең өчен, синең турында!

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

136 сум 15 тиен 1 айга

408 сум 45 тиен 3 айга

816 сум 90 тиен 6 айга

РЕСПУБЛИКАДА

КУКМАРА

Вахит авылының иң талантлы, тырыш ир-егетләре катнашында мәдәният йортында «Егетләр солянкасы» шоу-тамашасы узган. Бу проект биредә ел саен уздырыла икән. Тамашаны карарга 300дән артык кеше җыела. Егетләр җырлаганнар, биегәннәр, мәзәкләр сөйләгәннәр, күңелле видеоязмалар тәкъдим иткәннәр. 30дан артык катнашучы арасында төрле оешма хезмәткәрләре, мәктәп укучылары, пенсионерлар булган.

КАЙБЫЧ

Кайбыч мәктәбендә укучылар дәресләрдән соң балчыктан савыт-саба ясау белән шөгыльләнә. Технология һәм физкультура укытучысы Айдар Насретдинов ике еллар элек ачкан бу түгәрәкне. Ул кирәкле балчыкны үзе алып кайта икән. Әлегә балалар кечкенә чүлмәкләр, савытлар ясыйлар. Тагын да күбрәк эшләнмәләр ясар өчен зуррак мич булганны көтәләр.

ТЕЛӘЧЕ

Татар милли ашларын дөньяга танытучы Юныс Әхмәтҗанов Олы Кибәхуҗа авылында туып-үскән. Шуңа да якташларының тууына быел 90 ел тулу уңаеннан, Казаклар авыл китапханәсендә «Бәлеш бәйрәме» үткәргәннәр.

Бәйрәмдә хуҗабикәләр Юныс Әхмәтҗанов рецептлары буенча милли ризыклар пешергәннәр.Төрле ярышларда үзара көч сынашканнар. Аш-су әзерләүгә кагылышлы сорауларга, табышмакларга җавап биргәннәр. Юныс Әхмәтҗановның «Татар халык ашлары» китапларыннан күргәзмә дә оештырылган булган.

ЯШЕЛ ҮЗӘН

Шәһәрдә җәмәгать траспортын йөртүчеләр арасында беренче һәм әлегә бердәнбер хатын-кыз барлыкка килгән.

Ике бала әнисе Анжела Петровага сокланмаган кеше юк. Ул Яшел Үзәнгә Казаннан килеп эшләп йөри икән. Кыю ханым 2нче маршрут буенча пассажир автобусын йөртә. Пассажирларга карата игътибарлы, тукталышларны төгәл, диләр аның турында.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

БОЗ КУЗГАЛДЫ

«Татфондбанк»тагы вазгыять буенча уздырылган соңгы матбугат конференциясендә «ТФБ Финанс» клиентларының хокукларын «Татфондбанк» кертемчеләренеке белән тигезләү өчен юридик мөмкинлекләр эзләү турында хәбәр иткәннәр иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Татарстан прокуратурасы ике клиентның эшен Вахитов районы судына юллады. «Татар-информ» хәбәр иткәнчә, бу ике кеше «Татфондбанк»тагы кертемнәрен «ТФБ Финанс» бүлендегенә үзләре дә аңламыйча күчергәннәрен дәлилли алган һәм суд аларны банк кредиторлары реестрына кертергә дигән карар чыгарган. Нәтиҗәдә, бу кертемчеләр акчаларын Иминиятләштерелгән кертемнәр агентлыгы аша кайтару хокукына ия. Татарстан Прокуратурасы һәр кертемчене суд аша үз хокукларын кайтарырга өнди.

Ул арада «Татфондбанк» эшендә хокук саклаучылар 1,7 миллиард сумлык зыян салган тагын бер эшне ачыклады. Бу хакта Татарстан эчке эшләр министрлыгының икътисади куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы эшчәнлек идарәсе җитәкчесе Илдар Сафиуллин хәбәр итә. Бу вакыйга буенча процессуаль карар әлегә кабул ителмәгән.

Сүз уңаеннан, 21 март көнне Татарстан Дәүләт Советының 26нчы утырышында «Татфондбанк» темасына да сөйләшәчәкләр. Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белдергәнчә, хөкүмәткә банкка кагылышлы сораулар килгән. Утырыш кысаларында ул сорауларга аңлатма бирү мөмкинлеге булачак.

Балаларыбыз ничек туклана?

Шушы көннәрдә ТР Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында балалар бакчаларындагы туклануга кагылышлы темаларны күтәреп чыктылар.

Әлеге хезмәтнең Татарстан буенча идарә җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина китергән мәгълүматлар буенча, 2016 елда Россия Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек хезмәте Татарстандагы балалар бакчаларына азык-төлек китерә торган 93 оешманы тикшергән. Нәтиҗәдә 187 штраф салынган, аларның гомуми суммасы 1 млн сумнан артып киткән.

Моннан кала, Казанның азык-төлек һәм социаль туклану департаменты директоры Гүзәл Ананьева хәбәр итүенчә, ике мәктәптә тест режимында мобиль кушымта эшли башлаган. Аның ярдәмендә укучылар мәктәп ашханәсендәге ризыкларны бәяли, яңаларына тавыш бирә һәм үз фикерләрен калдыра алачак. Киләчәктә мондый кушымталарны башка белем бирү учреждениеләрендә дә булдырырга уйлыйлар. Нәтиҗәдә, мәктәп ашханәләренең рейтингы төзелгән шәһәр интерактив картасы барлыкка киләчәк.

Утырышта ризык блогындагы җиһазларны яңарту мәсьәләсе турында да сүз кузгатылды. Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Илдар Мөхәммәтов әйтүенчә, узган ел республиканың 53 балалар бакчасы капиталь төзекләндерелгән, быел тагын 110ысы яңартылырга тиеш. Әмма капиталь төзекләндерү кысаларында техник җиһазларны алыштыру планда каралмаган. Шуңа күрә аның хисабына техник җиһазларны да алыштыру мөмкинлеген бирә торган закон проекты эшләү кирәклеген әйтте ул. Бу турыда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка мөрәҗәгать белән чыгарга кирәк, дип саный министр урынбасары.

Шәһәр кәефе

РӘШИТ ӘХМӘТОВ,
мөхәррир:

– Арзамас шәһәрендә туып-үстем. Казанда 1965 елдан яшим. Авиация институтында инженер-механик белгечлеге үзләштергәч, биредә калдым. Яшьрәк чакта җәмәгать эшләре активисты идем, шәһәр Советы депутаты да булдым. Казанның бөтен дөньяның үзәгенә әверелүенә шаһитмен. Париж, Рим, Мадрид шәһәрләреннән мәдәни яктан калышуыбыз вакытлы күренеш кенә ул. Җәйне нык сагындым, чөнки җәй буе бакчада казынам.

РӘМИЛӘ СӘГЫТДИНОВА,
психолог:

– Казан күңел халәтемә бик тәңгәл. Бирегә мин, укырга дип, Ульян каласыннан килгән идем, ул мине беренче күрүдән үк пөхтәлеге, матурлыгы белән әсир итте. Бер күрүдә гашыйк булу инде бу. Монда тарихи урыннар да җитәрлек, заманча биналар да төзелеп тора. Төзекләндерелгән паркларны яшьләр аеруча үз итте. Соңгы вакытта әкиятләр язу белән мавыгып киттем. Шуның белән бергә лексиконыма әкият терапиясе дигән төшенчә дә килеп керде.

ЮЛЯ КОСОЛАПКИНА,
журналист:

– Казанның Киров районы кызы мин. Иске торaклары күп булса да, туган районым күңелемә якын. Адмиралтия бистәсенең туристлык комплексы сыйфатында төзекләндерелүен түземсезләнеп көтәм. Велосипедта йөрергә яратам. Алтай краена, Байкал күленә сәяхәтем гомергә онытылмаслык тәэсирләр калдырды. Европаны йөреп чыгарга хыялым бар.

АННА ЯКОВЛЕВА,
хезмәткәр:

– Чувашия дәүләт университетын тәмамлагач, шактый гына курсташларым Мәскәүгә китте. Мин, ике дә уйламыйча, Казанга юл тоттым. Татарстан – күршебез, кайтып йөрергә дә якын. Казан – зур мөмкинлекләр шәһәре. Биредә гаиләле булдым. Казан кешесе дип саныйм үземне. Казанны яраттым, куанып яшим, эшлим. Мәскәүгә киткән иптәшләрем миннән дусларча көнләшәләр хәтта. Казанга кайтыгыз, дим аларга.

ТИМУР МУСАБИРОВ,
парикмахер:

– Казанда яши башлаганыбызга – җиде ел, үзем Башкортстаннан. Кешенең, әлбәттә, беренче чиратта күңеле бай булу зарур. Ләкин тышкы матурлык та кирәк. Чиста-пөхтә йөргән кеше башкаларда уңай тәэсир калдыра. Быел җәйге ялда чит илгә бармабыз, мөгаен. Башкортстанга кайтып ял итәргә исәп. Туган нигездә, балта-пычкы тотып, нәрсә дә булса майтарып йөрү дә ял бит ул. Югары тизлекле тимер юл төзелгәч, аралар якынаячак.

Ана капиталына – машина

2017 ЕЛДА АНА КАПИТАЛЫ – 453 МЕҢ СУМ

Ана капиталын 4 юнәлеш буенча кулланып була

Ана капиталы программасына үзгәрешләр кертергә уйлыйлар. 23 март көнне Дәүләт Думасында бу темага закон проектын караячаклар. Депутатлар ана капиталын балага 18 яшь тулганчы ай саен бүлеп түләргә тәкъдим итә. Дөрес, кайбер җитәкчеләр моның белән килешми.

Башта Россиядәге гаиләләрнең бу пособиегә мохтаҗмы-түгелме икәнен ачыкларга кирәк дип саный. ЛДПР партиясе вәкилләренең исә ана капиталына карата үз тәкъдимнәре. Күпбалалы гаиләләргә, инвалид балалары булганнарга ана капиталын машиналата бирү кулайрак булыр иде, ди алар. RT хәбәр итүенчә, биш һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләргә коммуникацияләре тоташкан җир кишәрлекләре, ә гаиләдә җиде һәм аннан да күбрәк бала булганда «ГАЗель» машинасы бирү отышлы булыр иде дип уйлыйлар. Ә сезнеңчә ничек? Ана капиталын ничек түләсәләр яхшырак дип саныйсыз?

Илназ БАҺ,
җырчы, өч бала атасы:

– Иң кулае – ана кипиталын акчалата алудыр. Җир кишәрлеге, машина тапшырылган очракта да, аны сатып булмас иде. Капитал бит балага каралган. Төрле кеше төрле нәрсәгә мохтаҗ. Без, мәсәлән, үзебез ана капиталын торак шартларын яхшыртуга тоттык.

Әдилә ВАФИНА,
тәрбияче, өч бала анасы:

– Бүген күп гаиләләр торакка мохтаҗ. Шуңа да ана капиталын күпләр торак шартларын яхшырту өчен куллана. Акча урынына фатир бирсәләр, тагын да яхшырак булыр иде. Ул очракта туучылар саны тагын да артачак. Машина бирсәләр дә начар түгел. Үзем, мәсәлән, акча урынына машина алыр идем.

Гаяне ТОПЧАН,
хуҗабикә, өч бала анасы:

– Безнең Абхазия Республикасында икенче, өченче туган балага да дәүләттән андый ярдәм каралмаган. Шуңа да без нәрсә бирсәләр дә, риза булыр идек. Хәер, безнең якларда акча бирмәсәләр дә, күпбалалы гаиләләр шактый. Үземә, ана капиталын алыр өчен, Россиядәге туганнарымда теркәлергә туры килде. Бу дәүләт ярдәме киләчәктә дә булсын иде.

Конфедерация кубогы вакытында шәһәр юл-транспорт хәрәкәтенә үзгәрешләр кертелә. Матч булган көннәрдә җәмәгать транспорты дүрт сәгатькә озаграк эшләячәк. Шулай ук «Казан» аэропортыннан тимер юл вокзалына кадәр өстәмә ике автобус маршруты кертелә. «Казан – аэропорт» маршрутындагы электричка исә аэропортка кадәр туктамыйча барачак. Моңа өстәп, аэропортта өстәмә терминал булдырылачак.

Бушка йөрисең киләме?

Татарстанның транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары Андрей Егоров шәһәр халкына ярышлар барган вакытта шәхси транспорттан баш тартырга киңәш итте.

– Казанның кайбер урамнарында юллар ябылу сәбәпле, халыкка җәмәгать транспортында йөрү кулайрак булачак. Спорт объектлары территориясенә дә шәхси транспортта килү чикләнәчәк. Матчларга билет алганнар һәм волонтерлар ФИФА таләбе буенча Универсиада, Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионатындагы кебек җәмәгать транспортларында бушка йөриячәк. Моның өчен пассажир билет һәм җанатар паспортын тәкъдим итәргә тиеш. Транспорт өчен чыгымнарга республика бюджетыннан 35 миллион сум акча бүлеп бирелде, – диде Андрей Егоров.

Алисә САБИРОВА.

Кальяннарга көн бетә

Россия Дәүләт Думасына кальян, электрон сигаретларны сату, кулланыну чикләү турында закон проекты тәкъдим ителгән иде. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы исә бу законны тулысынча хуплаган, дип хәбәр итә «Российская газета». Министрлыкның җәмгыять сәламәтлеге һәм коммуникацияләр департаменты директоры Олег Салагай әйтүенчә, кальянны, электрон сигаретларны тәмәке белән бер дәрәҗәдә куеп, аларга карата чикләүләр кертү министрлыкның сәясәтенә туры килә. Әлеге закон проекты нигезендә кальяннарны, электрон тәмәкеләрне эштә, бина эчендә, җәмәгать урыннарында тарту тыелачак. Шулай ук кино, спектакльләрдә дә бу күренешне күрсәтергә ярамаячак.

Табиблар әйтүенчә, кальянда, гадәти тәмәкедәге кебек, никотин бар. Шуңа да кеше аңа ияләшә. Шулай ук кальян тарту йөрәк-кан тамырлары авырулары, инсульт, инфаркт китереп чыгарырга мөмкин. Татарстанның баш пульмонологы Александр Визель әйтүенчә, электрон сигарет тарту кеше организмына зыянлы җитештерү тармагында эшләгәндәге кебек үк тискәре йогынты ясый дип саный.

ТОП – 5

КИЕВТА 9 һәм 11 майда узачак «Евровидение» җыр бәйгесенең ярымфиналында Россия исеменнән җырчы Юлия Самойлова чыгыш ясаячак. Ул «Flame Is Burning» җырын башкара. Юлия балачактан инвалидлар арбасында гына хәрәкәт итә. Күпләр аны Алла Пугачеваның «Фактор А» проектында катнашуыннан да хәтерлидер. Бәйгедә барлыгы 43 ил вәкиле катнашыр дип көтелә.

РОССИЯ һәм Мисыр арасында туризм өлкәсендәге элемтәләр ныгыр кебек. Ике якта очышлар иминлеге буенча хезмәттәшлек турында беркетмә проекты төзелгән. Дөрес, әлегә ул имзаланмаган, дип хәбәр итә Россия Транспорт министрлыгы. Бу исә үз чиратында туристлык турларының бәясенә дә тәэсир итми калмас дип фаразлыйлар. «Мисырга турларның бәясе «тыю» кертелгән вакытка караганда 30 процентка арзанрак булырга мөмкин», – диләр Россия туроператорлары ассоциациясендә.

АМЕРИКАДАГЫ коммерциячел булмаган EWG оешмасы үткәргән тикшерү буенча, 2017 елда сатуда иң күп химик матдәләр кушылган продукт булып бакча җиләге табылган. N+1 порталы хәбәр иткәнчә, «пычрак» җиләк-җимешләр арасында нектарин, виноград, груша, башкалар да бар. Тик бакча җиләгендә 20дән артык пестицид төре ачыкланган. Ә менә кибет киштәләрендәге экологик яктан чиста продуктлардан кукуруз, ананас, кәбестә, кивины әйтергә була.

ЛАТВИЯНЕҢ Рига шәһәре мэры Нил Ушаков социаль челтәрдә чит телләрдә аралашканы өчен штраф түләгән. Рига Думасы, социаль челтәргә латыш теленнән тыш рус телендә дә хәбәрләр куйганы өчен, Нил Ушаковка 140 евро штраф салынган.

КЫТАЙНЫҢ Урумчи шәһәрендә яшәүче Лю Фэй үзенең кәләше Ван Фанфанга бер миллион юань бәрабәренә (АКШның 159 мең доллары) 33 тонна авырлыктагы таш бүләк иткән. Лю Фэй акчаны фатир сатып алу максатында җыйган. Ләкин узган ел сәяхәтләре вакытында Ван Фанфан бер коллекционердагы галәмәт зур «метеорит»ка бик кызыккан. Шуны истә тотып, егет кәләшенә йөзек белән бергә әлеге гадәти булмаган ташны да бүләк иткән. «Мәхәббәтебез шушы таш кебек нык булсын!» – дигән Лю Фэй.

КҮРШЕЛӘРДӘ

БАШКОРТСТАН

2017 елдан Башкортстанда беренче баласы туган яшь гаиләләргә 300 мең сум акчалата социаль ярдәм тапшырырга җыеналар. Бу хакта Башкортстан башлыгы Рөстәм Хәмитов белдергән. Тиздән ул бу хактагы социаль түләү тапшыру турындагы карарга кул куячагын һәм ул бу елның башыннан балалары туган гаиләләрнең торак шартларын яхшырту өчен бирелəчәген искәрткән.

ЧУВАШИЯ

Ел азагына кадәр Чувашиядә 42 мең кешене эш урыны белән тәэмин итәргә уйлыйлар. Чувашиянең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы матбугат үзәге хәбәр итүенчә, бүген республикада 15 меңләп вакансия ачык. Аеруча тегүче, ташчы, эретеп ябыштыручы, табиб, инженер, менеджер кебек һөнәр ияләренә кытлык сизелә. Чувашия халкының күбесе күрше төбәкләргә – Татарстанга, Себер якларына, Мәскәү шәһәренә китеп акча эшли икән.

МАРИ ЭЛ

Бер ай тирәсе элек Йошкар-Олада сөт кухнялары ябыла башлаган. Хәзер ата-аналар сөт ризыкларын теркәлү урыны буенча балалар сырхауханәсеннән ала. Күбесе бу системаны җайлырак дип тапкан. Балага тиешле ризыкларны алу өчен участок табибыннан рецепт алырга кирәк, сөт кухнясына бару күпләргә ерак, уңайсыз. Ә монда барысы да бер урында. Тагын бер яңалык – хәзер балага бер яшькә кадәр бары махсус коры сөт катнашмаларын гына бирәләр. Сөт, кефир бирелми башлаган.

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Язның бер көне ел туйдырыр

Министрлар кабинетында узган брифинг әнә шундый сүзләрдән башланды. Чыннан да, тиздән авылларда кызу чор – язгы кыр эшләре башлана. Әлеге зур эшкә әзерлек турында журналистларга Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Илдус Габдрахманов сөйләде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Язны мин иртә килде дип әйтә алмыйм. Башка еллардан аермалы буларак, мартта температура бераз күтәрелеп, карны шактый эретте. Моның берниндидә зыяны юк. Алдагы көннәрдә һава торышында кискен җылыту көтелми. Язгы кыр эшләрен алдагы елларда-гыча ук башларбыз, дип фаразлыйбыз. Ә кар катламына килгәндә, көньяк-көнчыгыш районнарда, Балтач, Арча, Кукмарада республика буенча кар 20 процентка күбрәк яуды. Быелның тагын бер үзенчәлеге – башка елларны җил белән себереп, кар юл кырыйларына тулып бетсә, быел ул басу өстенә тигез ятты, – диде Илдус Габдрахманов, «Шәһри Казан» журналистының соравына җавап итеп.

Җитәкче әйтүенчә, бүген авылларда кыр эшләренә әзерлек тулы көченә бара. Республикада язгы кар суларын тоту буенча айлык игълан ителгән. Шушы вакыт эчендә җирләрне күбрәк ерып, кар суларын җиргә сеңдереп калырга кирәк. Бу исә уңышны тагын да күбрәк алырга ярдәм итәчәк. Кар суларын тоту, туфракны эшкәртү, чәчүлек орлыгы буенча проблемалар булмаса да, минераль ашламалар туплау һәм техника мәсьәләсендә бераз гына каршылыклар очрый икән.

– Техниканың кыр эшләренә әзерлеге начар түгел. Чит ил техникасы буенча гына проблемалар бар, чөнки запас частьларны кертү озак вакытны ала. Шулай да апрель башына әлеге мәсьәләләр дә чишелер дип уйлыйм, – диде ул.

Илдус Габдрахманов әлегә ягулык буенча мәсьәләнең дә чишелмәгәнлеген әйтте.

– Моңа кадәр ТАИФ һәм «Татнефть» берләшмәсе ташламалы ягулык бүлеп бирә иде. Хәзер бу мәсьәлә чишелеш стадиясендә. Товар җитештерүчеләр аны алачак, ләкин бәясе киләсе атнада гына билгеле булачак, – диде ул. – Конкрет районнарның әзерлегенә килсәк, һәр районда да берникадәр әзерләнеп бетмәгән эшләр бар. Мәсәлән, Яңа Чишмә, Әгерҗе, Кама Тамагы, Минзәлә һәм Баулы районнарында минераль ашламалар аз тупланган. Ә иң күп ашламаны Зәй районы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре әзерләгән – ул бер гектарга 106,3 кг тәшкил итә. Сарман районында бу күрсәткеч бер гектар җиргә – 90,8 кг, Тәтештә – 73,9, Буада – 67,1, Әтнәдә – 65, 2 кг.

Шул ук вакытта Илдус Габдрахманов минераль ашламаларга бәяләр арта баруын, узган ел ашлама кертү күләмнәре кимүе турында да әйтте.

– 2016 елда без бер гектар сөрүлеккә 44,5 кг ашлама керттек. Былтыр октябрьдә республика Президенты тарафыннан минераль ашламаны 65 кг нан да ким кертмәү бурычы куелды. Хәзер бу чиккә якынлаштык. Былтыр ел дәвамында барлыгы 44,5 кг керткән булсак, бүген инде без шушы вакытка 44,5 кг керттек, гәрчә былтыр бу чорда әлеге күрсәткеч 20 кг тирәсе генә иде, – диде Илдус Габдрахманов.

Соңгы елларда карабодайга ихтыяҗ туганлыктан, быел республикада әлеге культураны игү күләмен арттырмакчы булалар.

– Карабодайга бәяләр күтәрелү, аясә базарда карабодай ярмасының булмавы проблемалар китереп чыгара. Совет чорында карабодай басулары 100 мең гектарга җитә иде, соңгы елларда 10 мең гектарга кадәр кимеде, чөнки Алтайдан кирәк кадәр кереп бара иде. Әмма соңгы елларда карабодай игүгә караш үзгәрде. Бәяләр дә төште, – диде Илдус Габдрахманов.

Җитәкче әйтүенчә, узган ел республикада карабодай 26 мең гектарда чәчелгән, быел исә 30 мең гектарга җиткерергә уйлыйлар.

– Бөгелмәдә карабодайны сыйфатлы итеп эшкәртә торган комбинат бар. Безнең бурыч – карабодай белән үзебезне генә тәэмин итеп калмыйча, республикадан читкә чыгару. Шушы көннәрдә генә «Карабодайны кем җитештерәчәк?» дигән сорау куелды. Хуҗалыкларны стимуллаштыру мәсьәләсендә «2 коэффициенты»н куллананачакбыз. Ягъни алар дәүләт ярдәмен ике тапкырга күбрәк алачак. Һәр гектарга шундый ярдәм булачак, – диде ул.

Илдус Габдрахманов карабодайның нигездә Бөгелмә, Азнакай, Актаныш якларында игеләчәген җиткерде. Рапс, кукуруз, көнбагыш кебек культураларны 100 мең гектарда игү буенча программа быел да дәвам иттереләчәк. Бу культуралар мәйданы 100 мең гектардан артык булачак.

Гади авылның гап-гади бер абзые. Гомер буе туган авылында, атаана нигезендә яшәгән, иген иккән, ат җиккән, мал тоткан, балалар үстергән. Нинди уй-фикерләр белән яши икән ул бүген? Аның күңелендә моң-зармы, шатлык-куанычлармы? Авырмы бүген аңа яшәргә, җиңелме? Балтач районы Арбор авылыннан Фәләхетдин абзый Сәләхетдиновның сөйләгәннәрен газета укучыларыбызга ничек бар шулай тәкъдим итәбез.

Автор фотосы

АВЫЛ АГАЕ

АШЛАМА АШАП ТА ҮЛМӘГӘНМЕН

Бер уйласаң, мин әллә кайчан үләргә тиеш булганмын кебек. Гомерең бетмәсә, үлмисең икән. Сугыш еллары, ашыйсы килгәнгә чыдар әмәл юк. Әниләр амбар алдында чәчүлеккә орлык әзерлиләр. Бер генә бөртек булса да авызга эләкмәсме икән дип, мин – дүрт яшьлек малай, амбар алдына киттем. Ә анда зур тәпән белән он! Дөресрәге, мин шулай дип уйлап, учлап-учлап ашарга тотындым. Ә ул симәнәгә кушарга дигән ашлама булган икән. Шундагы апаларның берсе мине күреп, тиз генә өенә кайтып сөт алып килә һәм мәҗбүриләп эчерә. Шуннан косып исән калганмын. Икенче бервакыт черек бәрәңге эзләп елга арьягына чыккан идек, кайтуыбызга күпер киткән. Язгы ташу чоры. Субайлар өстенә басып чыгыйм дигәндә, суга төшеп киттем. Ул вакыттагы ташуларны күрмәгән кеше генә белмәс, елгалар тулып, зур ташкын булып ага иде. Багор белән эләктереп тотып алганнар, агып китәсе булганмын. Аннан кайткач, алмашка кием юк, юеш өс-баш язгы кояш җылысында кипканче чишенгән килеш тордым. Трактор астында да кала яздым, саный китсәң, күп инде андый хәлләр.

ЯШЬЛӘРНЕҢ АВЫЛДАН КИТҮЕ ӘТИ-ӘНИДӘН

Телевизорда «Таяну ноктасы» тапшыруы бара. «Нигә авыллар бетә, аның килачәге нәрсәдә?» дигән сорауга җавап эзлиләр. Телевизор эчендә керердәй булып утырам. Авылда эшләгән кеше миллионер була ала дип әйтер идем мине шунда чакырсалар. Кара син безнең тормышны, начармыни? Безнең кебек гади хезмәт кешесе шәһәрдә менә шундый йортҗир җиткереп яши аламы? Азмы кеше фатирында акча түләп, тар гына җирдә яшәүчеләр. Ә яшьләрнең авылдан китү сәбәпләрен иң элек әти-әниләрдән эзләргә кирәк. Бәхетне читтән эзләп йөрисе юк, бер җирдә дә әзерләп куймаганнар дип төшендереп үстерсәң, нигезне ташлап китәргә ашыкмаслар иде. Армиядә хезмәт иткәндә миңа да шунда калу мөмкинлеге туды. Бер кыз белән таныштым, тормышлары да көйле иде. Әнигә, мин калам, дип хәбәр иттем. Әни исә: «Ярар, улым, мин каршы түгел. Башта мине берәр җиргә урнаштыр инде», – дип җавап бирде. Менә шуннан соң уйга калдым, ничек әнине калдырып китим. Шулай итеп, авылга кире кайтып, үземә насыйп ярымны очратып, туган авылымда гомер кичердем. Өч кыз, бер ул тәрбияләп үстердек. Үземнең улыма да әйттем, зур акча эзләп йөрисе юк, илдә чыпчык үлми, аз гына акча түли торган эш бар икән, авылдан чыгып китмә, дидем. Менә кара әле син безнең каралты-кураны. Өч мунча гына бар. Газ мунчасы, утынныкы, терлекләргә азык пешерү өчен тагын аерым. Болай заманча итеп төзергә безнең баш җитеп бетмәс иде, яшьләр булдырдылар. Килен молодец безнең, бер кулында – кәгазь, икенчесендә – карандаш. Барысының сызымын сызып, үзе планлаштырды. Үзебез төзегән кызганыч бит инде. Яшермим, үзгәртеп төзи башлагач, йөрәк тузынган иде, бетерәләр дип уйладым, менә ничек итеп төзеп куйдылар.

АТ ҺӘМ БАСУ-КЫРЛАР МИНЕ ЯШӘТӘ

Ышанасыңмы-юкмы, яз җитүен минем хәтле көткән кеше юктыр. Тизрәк ат җигеп, басуга чыгасым килә. Аның рәхәтлеген әйтеп бетерерлек кенә түгел. Яратам мин атларны. Иртә яздан йөри башлыйбыз, кара көзгә хәтле көн саен ат җигәм. Басуларны әйләнеп кайтам да, ярый әле колхоз бар, дим. Бөтен кырларны эшкәртәләр, чәчәләр, уралар. Басулар буш булса, каян аласың? Әле монда көн дә бер әйләнәбез, нәрсә булса да ияреп кайта. Тегендә басу кыры, монда эскерт төбе, монда елга кырын чабып алабыз. Улыбыз хуҗалыкта эшли, аңа да бираләр, без алып кайтканы да иш янына куш була. Дөресен генә әйткәндә, терлеккә ашатырга булмаганнан йөрү түгел инде ул, җанга шулай рәхәт, күңел шулай тели. Гомер буе күп итеп терлек тоттык, әле дә шулай. Терлеге булса, акчасы да була. Сөтен җыялар, итен сатасың. Йөгәнне мин тоткач, Фәләхетдин абый гел ат белән йөри, эшли, диләр. Мин түгел, хатыным Рәхилә бик булган. Мин шул йөгән тотучы гына. Яшьләр дә бик тырыш, бездән генә булмас иде.

Тормыш бик матур, сеңлем. Менә хәзер Сабан туйлары җитәр. Үз чорында күрәштем дә, гер дә күтәрдем. Хәзер дә Сабан туена атымны чуклар белән бизәп төшәм. Күңел алдан ашкынып тора. Без Рәхилә апаң белән урманчылыкта бик күп агачлар утырттык. Аларның үсеп килүенә дә куанып йөрибез. Менә шулай яшәп ятабыз, кызым.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА язып алды.

Киләсе тема – «Күчемсез милек объектларын дәүләт кадастр исәбенә алу мәсьәләләре». Кызыксындырган сорауларыгызны **(843) 562-50-09** яки **8(986) 723-94-48** телефоннары аша редакциябезгә юллый аласыз.

СУБСИДИЯ: кемгә күпме тиеш?

Коммуналь хезмәтләр өчен түләү кәгазен күргә, андагы саннардан, кулланылган хезмәтләр исемлегеннән күзләр камаша. Аңлаган, аңлашылып бетмәгән урыннары да җитәрлек. Халыкка ярдәм йөзеннән, дәүләт төрле ташламалар тәкъдим итә. Аларны ничек рәсмиләштерергә? Коммуналь хезмәтләргә түләгәндә бирелә торган субсидия кемнәргә тиеш? Бүген сәхифәбездә укучыларыбыздан бу темага килгән сорауларга җавап бирәбез. Сорауларга Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Наталья БУТАЕВА аңлатма бирде.

Эльвира МОЗАФФАР

Коммуналь хезмәтләр өчен субсидия кемнәргә тиеш? Моның өчен нинди документлар җыярга кирәк?

Айсинә САФИУЛЛИНА,
Казан.

Россия Торак Кодексының 159нчы маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасында гражданнарга ярдәм итү максатыннан, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә ташлама-субсидияләр бирү каралган. Шул рәвешле, Татарстанда тарифлар буенча дәүләт комитеты карары нигезендә, коммуналь хезмәтләр өчен тотылган чыгымнары уртача айлык керемнәреннән 21 проценттан артып киткән гаиләләр әлеге субсидиягә дәгъва кыла ала. Субсидия алырга муниципаль яки дәүләт торак фонды торагыннан файдаланучылар, шәхси торак фондына караган торакта найм килешүе нигезендә яшәүчеләр, төзелеш торак кооперативы вәкилләре, фатир, шәхси йорт милекчеләре хокуклы булып санала.

Субсидияләр гражданнарның торак-коммуналь хезмәтләре өчен түләүләрдә бурычлары булмаган очракта бирелә. Субсидия алу өчен теркәлү урыны буенча социаль яклау бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Субсидия алу өчен кирәкле документлар (һәр гаилә әгъзасыннан да таләп ителә):

– гариза;

– гаилә составы турында белешмә;

– паспорт (күчерелмәсе) ;

– шәхси лицевой счетның иминият номеры (СНИЛС);

– теркәлү урыны буенча торактан файдалану һәм аны куллану хокукын бирә торган рәсми документлар;

– торак-коммуналь хезмәтләргә түләүдә бурычлар юклыгы турында белешмә;

– гаиләнең соңгы алты айдагы кереме турында эш урыныннан белешмә (2 НДФЛ);

– Саклык банкы яки «АК БАРС» банкта ачырылган шәхси счетның номеры. (Документлар исемлеген теркәлү урыны буенча социаль яклау бүлегеннән тулырак ачыкларга мөмкин.)

Шулай ук Теркәү паласыннан торакның милекчесе икәнне раслаган документ, уллыкка алынган бала турында белешмә кебек өстәмә мәгълүматлар да сората алалар.

Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр алу өчен гаиләдә бер кешегә тиешле керем ничә сумнан артмаска тиеш?

Миләүшә САБИТОВА,
Казан.

«Татарстанда торак һәм коммуналь хезмәтләргә түләгәндә халыкка өстәмә социаль ярдәм күрсәтү турында»гы 665нче закон нигезендә, бер кеше башына туры килгән уртача айлык керем 7 мең сумнан артмаска тиеш. Бу очракта гына кешеләргә торак-коммуналь хезмәтләргә түләгәндә субсидия каралган. Керем бер кешегә 3200 сумнан артмаганда, үзәкләштерелгән җылылыкка түләүләр өчен каралган субсидия бирелә. Болардан тыш 2009 елның 1 мартыннан соң электр энергиясен исәпли торган җайланманы куйдырган өчен дә бер тапкыр ташламадан файдалану каралган. Ул гаиләнең кеше башына туры килгән айлык кереме Татарстанда билгеләнгән яшәү минимумыннан артмаган очракта бирелә. Кайтарыла торган субсидия түләгән коммуналь хезмәтләр суммасына, гаиләнең айлык кеременә, шәхси факторларга бәйле рәвештә төрле була.

Бүген Татарстанда уртача яшәү минимумы ничә сум?

Министрлар кабинетының 2017 елның 26 гыйнварыннан кабул иткән карары нигезендә (№31), республикада уртача яшәү минимумы 8108 сум, эшли торган кешеләр өчен 8657 сум, пенсионерларга — 6644 сум, балаларга 8027 сум булып санала.

Коммуналь хезмәтләргә түләгәндә, инвалидларга, күп балалы аналарга нинди ташламалар каралган?

Ильяс ФӘРУКШИН,
Чаллы.

Коммуналь хезмәтләргә түләгәндә, республикада аерым категория гражданнарга ташламалар каралган. Субсидия күләме Россия һәм Татарстандагы хокукый-норматив актлар нигезендә билгеләнә. «Россиядә инвалидларны саклау турында»гы Федераль закон буенча, физик яктан мөмкинлеге чикле кешеләргә, инвалид бала булган гаиләләргә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә чыгымнарыннан 50 процент субсидия бирелә. Татарстанда билгеләнгән социаль торак мәйданы өчен коммуналь хезмәтләргә түләгәндә, 18 яшькә кадәр өч һәм аннан күбрәк балалары булганнарга 30 процент субсидия бирү каралган.

Мин фатирымның милекчесе булып саналам. Фатирда улым да теркәлгән. Ә мөнә киленебез теркәлмәгән. Социаль яклау бүлегенә аз керемле гаилә буларак субсидия алырга баргач, миңа киленнең документларын да җыярга куштылар. Бу законлымы? Ул бит безнең фатирда теркәлмәгән?

Зәйнәп ШӘРӘФИЕВА,
Казан,
Борисково бистәсе.

Россия Хөкүмәте карары нигезендә, субсидияне билгеләгәндә, барлык гаилә әгъзаларының соңгы алты айлык керемнәре кушылып исәпләнә. Сез йортның милекчесе, сез дә, улыгыз да торакта теркәлгән. Димәк, субсидия алу өчен, улыгызның да, үзегезнең дә документларын җыярга кирәк. Улыгыз өйләнгән булу сәбәпле, аның белән бергә яшәгән хатынының керемнәре дә исәпкә алына. Шул рәвешле, социаль яклау бүлегенә сез киленегезнең документларын да китерергә тиеш.

Мин Даурия урамында яшим. Безнең бер бүлмәле фатирыбыз бар. Декабрь аенда авылга яшәргә кайтып киткән идек, тик коммуналь хезмәтләр өчен барыбер түләүләр килгән. Житмәсә 3 мең сум тирәсе. Утка, суга исәпләү җайланмасы урнаштырылган. Ирем – III төркем инвалид. Ни өчен коммуналь хезмәтләр өчен шундый зур сумалар түлибез? Хәтта кар көрәгән өчен дә бездән акча алганнар, югыйсә декабрь ае буе фатирда яшәмәдек.

Минфирдия ГАФИЯТОВА,
Арча.

Минфирдия апа соравы буенча алар яшәгән йортка хезмәт күрсәтүче «Территория комфорта» идарәче компаниясенә мөрәҗәгать иттек.

Кар көрәү мәсьәләсенә килгәндә, компания хезмәткәрләре аңлатканча, декабрь аенда чынлап та һәр фатир хуҗасына өстәмә хезмәт өчен акча исәпләнгән. Торак инспекциясе карары белән, карны күпләп читкә чыгару бурычы куелган булган, шуның өчен читтән махсус техника җәлеп итәргә туры килгән. Карны чыгарган өчен, килешү нигезендә законлы төстә, һәр фатирның торак мәйданына бәйле рәвештә түләүләр билгеләнгән. Бу йортта яшәүчеләр белән килешенеп эшләнгән – кар чистарту турында алдан хәбәр ителгән, җыелыш үткәрелгән.

– Гафиятовлар фатирда ике кеше теркәлгән. Аларга торак-коммуналь хезмәтләр буенча түләүләр исәп җайланмалары күрсәткечләре нигезендә билгеләнә. Күрсәтмәләрдән күренгәнчә, Гафиятовлар сентябрь аеннан бирле ут өчен ай саен билгеле бер күрсәткечләр тапшырып барганнар. Бары декабрь аенда гына күрсәткечләр 14 киловаттка арткан. Мөгаен, бу киловаттлар бер айда гына түгел, сентябрьдән ноябрьгә кадәр җыелган саннардыр. Тик бу турыда бер айда гына хәбәр ителгәч, түләү күп исәпләнгән кебек тоелырга мөмкин. Кыскасы, без бары яшәүчеләрнең үзләре биргән күрсәткечләре нигезендә генә ут, су өчен түләүләр билгелибез. Нәрсәдер аңлашылмаса, яшәүчеләр Даурия урамы, 44 «в» адресы буенча урнашкан бинабызда 7нче офиска килә ала. Гаиләдә физик яктан мөмкинлекләре чикле кешеләр булганда, социаль яклау бүлегенә ташлама сорап, документлар тапшырырга да мөмкин. Коммуналь хезмәтләргә түләгәндә, сезгә субсидияләр билгеләнер иде, – диде «Территория комфорта» идарәче компаниясе хезмәткәре.

Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрдә сорауларыгыз туса, «Идарәче йорт – грамоталы кулланучы мәктәбе»нә мөрәҗәгать итә аласыз. Кулланучы мәктәбе үзе дә халыкка аңлату курслары уздыра. Курсларга **8 (843) 236-29-97** телефоны аша язылырга була. Кулланучы мәктәбендә лекцияләрне республиканың Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, кулланучылар хокукларын яклау идарәсе, Казан шәһәренең тарифлар, торак-коммуналь хуҗалыгы комитеты белгечләре укый. Татарстанда әлеге мәктәптә теләгән һәркем бушлай укый ала.

Язмамның геройлары депутатлар да, очучылар да, генераллар да, мәшһүр җырчылар да түгел, гап-гади хезмәт кешеләре – эшче династиясен дәвам итүчеләр. Гади, булдыклы, тырышлар. Шул ук вакытта бик тату, үрнәк гаилә дә. Гаиләләре белән танышырга теләвебезне әйткәч тә, Сәет абый иң башта, аның нәрсәсен язасың инде, без йолдызлар түгел бит, дип әйтеп куйды. Нәкъ менә сезнең турында язасыбыз килә дә инде, дигәч, тиз көнде тагын, очрашу өчен уларының ял вакытлары бергә туры килгән көнне билгеләп, үзләренә кунакка чакырды. Сәет һәм Ринат Гафуровлар өчен Казан моторлар төзү заводы туган йортлары кебек. Әти-әниләре шунда эшләгән, үзләре заводта күп еллар хезмәт куйган, хәзер аларның эшләрен уллары, киленнәре дәвам итә, хатыннары ягыннан да туганнары шунда.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

ХЕЗМӘТ БАТЫРЛАРЫ

Гафуровлар-Ганиевларның заводтагы хезмәт стажлары – 267 ел!

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

«ЗАВОД БЕЛӘН ТАНЫШУ КӨРӘКТӘН БАШЛАНДЫ»

Беренче булып заводка сукмакны аларның әтиләре сала.

– Әтиебез Самат заводка 1951 елны килгән, анда ул металл кою цехында эшли. Формовкалаучы да, калыплар әзерләүче дә, эретеп ямаучы да була. Соңрак заводта әниебез Гөлҗиһан да эшли башлый. Аның бертуганы Тәскирә апа да шунда эшләгән. Өйдә олыларның сөйләшүләре гел шул завод тирәсендә иде. Ике җөмләнең берсендә сүз көрәкләр турында барды. Безнең дә завод белән танышуыбыз шул «көрәк» сүзеннән башланды. Алар сөйли торган көрәкне бакчада җир казыганда кулланыла торган көрәк дип уйлый идек. Бервакыт әтидән, шуның кадәр көрәк нәрсәгә кирәк соң, дип сорыйм аптырап. Без самолет двигательләре ясыйбыз, аларның моторларына берничә төрле көрәк куела, дип аңлатты ул энем белән миңа, – дип сөйли Сәет абый.

Абыйлы-энеле икесе дә заводка мәктәпне тәмамлауга ук килә. Әйтүләренчә, хәзер эшчеләргә кытлык заманасы булса, ә ул вакытта заводка эшкә керү ансат булмаган.

– Авылдан килүчеләрне тулай торак көтеп тора, хезмәт хакын вакытында алып барасың, шифаханәләргә юллама бирәләр, ял базаларына бара аласың, тырышып эшләсәң, мастер итеп куялар, эшеңне бәялиләр. Ирләр пенсиягә – 50дә, хатын-кызлар 45 яшьтә китә иде. Ул чорда заводка эшкә сайлап кына алдылар. Әти-әниебез намуслы хезмәт белән танылгач, безгә анда урнашу авыр булмады. Армиягә кадәр шунда эшләп алырга булдык. Сәет эшкә бер проблемасыз гына урнашты. Ә менә мин әтигә бер сүз дә әйтмичә генә кадрлар бүлегенә барган идем, яшемне сорадылар. 17 дигәч, син әле яшь, армиядән соң килерсең, бездә эшчеләр җитәрлек, диделәр. Әти икенче көнне үк мине эшкә урнаштырып та кайтты. Армиядән соң да туры заводка кайттык, – дип, сүзгә кушыла Ринат абый.

Заводта ул – 20, ә Сәет абый 41 ел эшләгән, «СССРның хезмәт ветераны» исемен алган. Үзенең якынча исәпләүләре буенча, заводта эшләгән чорында аңа барлыгы алты мең көрәк эшләргә туры килгән. Цехта полировкалаучы һөнәре иң авырлардан санала. Анда акча да күп түләнгән. Әтиләренең киңәшен тотып, Сәет абый шунда эшләгән.

– Эш бик авыр, аның каравы хезмәт хакы югары булды. Дүрт ел эчендә фатирлы да булып куйдым, – ди ул. – Эшләгән вакытта авиация техникумында укыдым. Көрәкне эшләп бетермичә, өйгә кайту юк. Укырга барырга да вакыт кирәк. Мин иртәнге биштә үк, аннары ял көннәрендә дә эшкә килә идем дә запас көрәкләр ясап куя идем. Өлгерә алмаганда, шуларны тапшырып кайтып китәм, – дип искә ала ул заводта узган яшь чакларын.

ЭСТАФЕТАНЫ ДӘВАМ ИТҮЧЕЛӘР

Аларның хезмәт юлын бүген уллары дәвам итә. Ринат абыйның уллары Радик белән Руслан шулай ук 16нчы цехта эшлиләр. Бирегә эшкә килүләренә ун ел булган. Заводка икесе дә бер үк вакытта диярлек урнашкан. Радик башта авиация техникумын тәмамлаган. Абыйлы-энеле мичтә стерженьнәр әзерлиләр, алар әлеге дә баягы шул көрәкләр өчен мөһим булган деталь булып тора.

– Әби-бабай, әти, Сәет абыйларның эшен дәвам итү үзенә күрә бер җаваплылык та өсти. Хезмәт династиясе исемен йөртүчеләр бит без. Кем балалары дип сораганда, горурланып, Гафуровлар дип әйтерлек булсын! – ди Радик.

Русланның хатыны Алена да заводта эшләп декрет ялына киткән. Алар бер үк цехта эшләгәннәр. Аленаның туганнары арасында да заводта эшләүчеләр бар икән.

Рамил – Сәет абыйның улы. Аның заводка килүенә 11 ел була. Ул да әтисе кебек үк полировкалаучы, ягъни детальләрне шомартып ялтыратучы.

– Мин заводка өч тапкыр барып карадым. Әти башта ук шунда чакырган иде. Яшьлек белән аңлап бетермәгәнмен. Төзелештә эшләп йөрдем, сезон булганда эш бар, булмаганда – юк. Шуның белән бәйле рәвештә хезмәт хакында да тотрыклылык юк. Өйләнгәч, ике дә уйламыйча, заводка эшкә килдем. Гаиләне алып бару өчен ир-атка төпле эш урыны кирәк бит. Эш шартлары бабайлар, әтиләр эшләгән вакыттагы кебек түгел, күпкә яхшы, – ди ул.

Аның сүзләренә караганда, заводта яшьләр өчен спорт белән шөгыльләнергә дә бөтен мөмкинлекләр бар. Төрле спорт секцияләре эшли, ярышлар һәрдаим оештырыла. Рамил күп еллар «ТР Профавиа» җыелма футбол командасында уйнаган.

Моторлар төзү заводында Сәет абыйның хатыны Сания апаның әти-әнисе дә эшләгән. Заводка алар артыннан уллары Рәфыйк һәм аның хатыны Рәсимә дә килгән. Рәсимә апа металл кою цехында әле дә эшли. Уллары Роберт та авиация техникумын тәмамлаган, Гафуровлар династиясе кебек үк, 16 нчы цехта эшләгән. Заводка Рәсимә белән Рәфыйк Ганиевларның кызлары Рузалия дә килгән, ул монда инженер булып эшли. Күптән түгел генә заводка инде дүртенче буын вәкиле Фәрхад тә килгән. Биредә ул – юрист-консультант ярдәмчесе.

БЕРТУГАННАР – ГЕЛ ТУГАННАР

Гафуровларда бер генә бәйрәм дә гармуннан башка узмый. Гаилә бәйрәмнәренә туганнар бергә җыелып, табын артында җырлап утырырга ярата. Шуңа да Сәет абый гармунын үзеннән калдырмый. Гармунчы исә бөтен табынны тотып тора.

– Элек завод яшьләре татар дискотекаларына җыела иде. Гармунга биетә идем барысын да. Хатыным белән дә шунда таныштым. Без генә түгел, күп яшьләр шунда кавыша иде. Эх, күңелле чаклар булган! – дип елмаеп куя ул.

Заводта эшләгәндә дә концерт программалары аннан башка узмаган. Хәзер дә аны бәйрәмнәргә гел чакырып торалар. Ул әле дә Ленин исемендәге мәдәният йорты каршындагы баянчылар ансамбленә йөри. Аларны шәһәр күләмендә узган бөтен бәйрәмдә дә күрергә була.

Сәет белән Ринат Гафуровлар бакча күршеләре дә икән әле.

– Заводта да, бәйрәмнәрдә дә, хәтта җәй җиткәч, бакчада да без бергә. Әти-әни дә безгә, туганлыкны суытмагыз, берберебезгә терәк булыгыз, дип әйтә килде. Бу дөньяда туганыңны беркем дә алыштыра алмый, – ди алар.

Игелекле җаннар җыены

Галимнәр, серләр эзләп, тирән диңгез-океаннарга төшәләр, карашларын иксез-чиксез күккә төбиләр. Ләкин иң серле дөнья ул – кеше күңеле, аның җаны, йөрәгедер, күрәсең. Тәрбиягә бала алган әти-әниләрнең V Республика форумында нәкъ менә шундый олы йөрәкле игелекле җаннар җыелган иде.

Мөмкинлекләре чикләнгән биш ятимне тәрбияләүче Елена Җафарова (уртада).

Форумның беренче өлеше рәсми үтте. Анда Татарстан Дәүләт Советы рәисе урынбасары Татьяна Ларионова, Балалар хокукы буенча вәкаләтле вәкил Гүзәл Удачина, Татарстан мәгариф министры урынбасары Лариса Сулима һәм башкалар чыгыш ясады. Татьяна Ларионова үз чыгышында, республикабыз ятимнәренә аталарча кайгырту күрсәткәне өчен, Президент Рөстәм Миңнехановка рәхмәтен җиткерде. Дәүләт Советы рәисе урынбасары авызыннан Рөстәм Нургали улының мөмкинлекләре чикләнгән балаларны уллыкка-кызлыкка алырга тәвәккәлләгән гаиләләргә бер тапкыр 200 мең сум акча бирергә җыену хәбәрен ишетү табигать тарафыннан рәнҗетелгән сабыйлар язмышы өчен күңелләрдә өмет уятты. Чөнки гаиләдә яшәү бәхетеннән башлыча нәкъ менә алар мәхрүм кала да инде. Ә болай безнең республика халкы ятим балаларга шактый мәрхәмәтле. 11717 ятим баланың 11150се гаиләләрдә яши. Узган ел гына да 1192 бала яңа әти-әниле булган. Республикабызның 8777 гаиләсендә тәрбиягә алынган балалар үсә. Ә бит элек алар бармак белән генә санарлык аз иде. Әлеге сөенечле саннар артында сабыйларның кабаттан елмаерга өйрәнүләре, өлкәннәргә ышанычлары кайту торуын уйласак, бу – шактый куанычлы нәтиҗә. Балага үсәр өчен гаилә кирәклеген берәүгә дә аңлатып торасы юк. Шуңа күрә дә хөкүмәтебез мондый игелекле гаиләләргә булдыра алган кадәр ярдәм итәргә тырыша. Шактый еллар рәттән уздырыла торган әти-әниләр һәм балаларның җәйге ял сменасы – мондый гаиләләрне бергә туплау, туган проблемаларын бергәләп чишәргә ярдәм итәргә тырышуның бер юлы. Мондый лагерь быел да ике сменада эшләячәк.

Форумның икенче өлешендә сүз тәрбиягә бала алган гаиләләрнең үзләренә бирелде. Бу теманы алардан да әйбәтрәк белүче кеше юк. Шуңа да күңелдәгеләрен ачып салдылар. Яшел Үзән районы Норлат авылыннан 12 ятим балага (икесен әле күптән түгел генә алганнар, берсенең мөмкинлекләре чикле) җылы кочагын ачкан Рәйсә Миңнуллинаның чыгышын зал алкышларга күмде. «Кем кайда эшли шуннан алып кайта инде...» – ди ул, шаяртып. Һәм бу сүзләрдә хаклык та бар. Норлат балалар йортында эшләгәч, ул күңеленә кергән һәр баланы үзенеке итәргә тырышкан. Рәхмәт, ире Наил әфәнде дә каршы килмәгән. Аның үрнәгенә башка хезмәттәшләре дә ияргән. Шулай итеп, кайчандыр 100ләп сабый яшәгән ятимнәр йортында хәзер аларның саны 40ка да тулмый. 28е Рәйсә ханым шикелле игелекле әти-әниләрнең гаиләләрендә сыену урыны тапкан. Рәйсә ханым үзләренең районнарында тәрбиягә бала алган 100ләп гаиләне берләштерүче оешманың рәисе дә әле. Алар тирә-күрше районнарга чыгып, чит баланы да яратырга мөмкин булуын аңлаталар. «Һәр өлкән кешенең максаты бер булырга – һәр бала гаиләдә яшәргә тиеш!» дигән фикерне алга сөрә алар.

Кукмарадан «Игелек» оешмасы җитәкчесе – өч ятимгә ана булган Роза Шәйхетдинованың да горурланып сөйләр сүзләре күп. Балаларның берсе Мәскәүдә Халыклар Дуслыгы университетында укый. Районның 32 гаиләсендә 57 бала бәхетле булып үсә.

Яшел Үзәндә яшәүче Шубин-Мордовиченколар гаиләсе җиде ятим малайга (!) җылы оя гына түгел, тормыш дәресе дә бирә. Әти-әниләрен шатландырып, егетләр спорт белән дә шөгыльләнәләр, кул арасына кереп, эш кораллары тотарга да өйрәнәләр. Видеороликтан күреп, без алар өчен чын күңелдән сөенеп утырдык.

Света һәм Марсель Халиевлар гаиләсе бертуган өч сабыйны Оренбург өлкәсе Орск шәһәренең балалар йортыннан алып кайткан. «Икәү бардык, бишәү кайттык», –ди алар, ул көннәрне искә төшереп. Югыйсә, бер бала алабыз дип кенә барган булганнар. Алар аласы баланың туганнары барлыгын баргач кына белгәннәр. Ләкин сабыйлар бер анадан булсалар да, туганлык җепләре өзелгән булган: төрлесе төрле төркемдә яшәгәннәр. Әти-әнигә аларның туганлык хисләрен яңадан уяту өчен шактый тырышырга туры килгән.

Айсылу Чижевская гаиләсендә тәрбияләнгән Даниэл НТВ каналында бара торган «Ты супер!» тапшыруында катнашып, Филипп Киркоров белән бергә чыгыш ясаган. Әгәр дә бу сабыйлар шушындый кайгыртучан гаиләләргә эләкмәгән булсалар, аларның язмышлары ничек булыр иде икән?..

Форумга делегат булып килгән гаиләләрнең һәрберсе турында укучы кулыннан төшерми укый торган китап язарлык.

Форумнан мин зур сөенеч белән кайттым. Кайчандыр телефон аша гына танышып аралашкан Әтнә районы Бәрәзә авылыннан Радалия ханымның да хыялы чынга ашкан: ул дүрт сабыйны җылы кочагына алган. Түбән Камадан ун яшьлек Рома (кул чуклары җилкәсеннән үсkәнгә, аны яратып «канатлы малай» дип йөрткәннәр) да бүген бик бәхетле булып, әни кочагында Новосибирск өлкәсендә яшәп ята. Димәк, ятимнәребез саны тагын бишкә кимегән. Шулай бергәләп тырышсак, алар бөтенләй дә булмас әле. Бу көнне якынайтуда мондый форумнарның әһәмияте әйтеп бетергесез.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Хатын-кызларның үз «Бишеге» булачак

Татарстанда авыр хәлдә калган, баласыннан баш тартырга теләгән хатын-кызларга ярдәм итү максатыннан, йөклелекне өзүгә каршы чаралар күп уздырыла.

Эльвира МОЗАФФАР

Абортның зыяны, ул китергән аяныч нәтиҗәләр турында хатын-кызларга яшьтән сөйләсәң, авыр хәлдә калган булачак аналарга ярдәм күрсәтү юлларын эзләсәң, бу мәсьәләне хәл итү күпкә җиңелләр иде, дип саный белгечләр. Бу максаттан республикада җиденче ел «Умиление» кризис үзәге эшләп килә. Йөклелекне саклап калу – кризис үзәге эшенең бер юнәлеше генә. Моннан тыш алар күп балалы, авырлы, авыр хәлдә калган хатын-кызларга да булышалар. Төп максатлары – гаиләне, авыр хәлдә калган хатын-кызларның, балаларның хокукларын яклау, баласыннан баш тартырга теләүчеләр белән психологик эш алып бару.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, еш кына хатын-кызлар белән бер утырып сөйләшү, күңелендәгесен тыңлау туачак баланың язмышын хәл итә ала. Иң мөһиме – хатын-кыз үзен ялгыз хис итмәсен, дип саный үзәк хезмәткәрләре.

Үзәктә гуманитар ярдәм склады эшли. Бирегә балалар өчен кирәк-яраклар – коляска, уенчыклар, кием-салым, подгузниклар алып килергә мөмкин. Аларны мохтаҗ кешеләргә өләшәләр.

Статистика буенча, Россиядә ел саен 700 меңләп аборт ясала. Ел саен дөньяда 70 мең хатын-кыз аборттан соң өзлегүләрдән үлә.

«Умиление» кризис үзәге психологлары ике ел эчендә 60 хатын-кызны аборт ясату уеннан үгетли алганнар. Үзәк турында интернетта социаль челтәрләрдә җитәрлек мәгълүмат урнаштырылса да, хатын-кызларның күбесе ярдәм сорап килергә уңайсызлана, ояла. Шуңа да үзәкнең психологлары еш кына үзләре хатын-кызлар консультацияләренә баралар, Казанның бала тудыру йортлары белән хезмәттәшлек итәләр.

– Безнең белгечләр авырлы хатын-кызларга махсус видеоролик күрсәтә. Анда яралгының үсеше тасвирланган. Хатын-кызларга психолог ярдәме йөккә узуын белгән чактан ук кирәк. Ул аборт турында карар кабул итеп өлгермәсә яхшырак, чөнки ныклы карарга килгән хатын-кызны уеннан кире кайтару шактый катлаулы. Берсендә бер хатын, баласы туганчы, сабыен төшертергә теләде. Көненә кабы белән тәмәке тартып бетерә иде. Шөкер, бала сәламәт туды. Иң мөһиме – ул әнисенең дөньяга карашын үзгәртә алды. Хәзер бу хатын баласын бик ярата, – ди үзәкнең җитәкчесе Элина Галиуллина.

Үзәктә авырлы хатын-кызларга, яшь балалы мохтаҗ аналарга торак белән дә ярдәм итәләр. 2016 елга кадәр гамәлдә булган «Кризислы фатир» проекты буенча хатын-кызларның кайберләренә хәтта ел дәвамында вакытлыча фатир алып торган кризис үзәге. Киров өлкәсе, Башкортстан Республикасыннан мөрәҗәгать итүчеләр дә бар. Авыллардан Казанга акча эшләргә килгән авыр хәлдә калган хатын-кызлар да бар монда. Шулай ук егете ташлаган, авырга узган кызлар, ире кыйнаган хатыннар да үзәктә сыену таба.

Апрель аенда «Умиление» үзәге авыр хәлдә калган хатын-кызлар өчен приют ачарга җыена. Хәер, Элина Галиуллина «приют» сүзен яратып бетерми, бу хатын-кызларны куркыта, дип саный. Шуңа да оешманы «Бишек» («Колыбель») социаль йорты дип атаганнар. Биредә социаль тернәкләнү узарга: психолог консультациясе, юрист киңәше алырга мөмкин булачак. Шулай ук кул эшләре – чигү, тегү, бәйләү белән дә шөгыльләнү курслары оештырырга уйлыйлар. Йортта кимендә алты хатын-кыз яши алачак. Биредә аларга өч ай дәвамында калырга була, дөрес, авырлы хатын-кызларның хәленә карәләр, аларга тормышлары җайга салынганчы яшәү мөмкинлеге биреләчәк.

«Умиление» үзәге психологларына 8-987-22-00-360 номеры аша шалтыратырга мөмкин. Консультация, шалтырату бушлай. Гуманитар ярдәмгә кагылышлы сораулар өчен телефон: 216-76-19.

Кайчандыр дермантин сумкасын тотып: «Фасоны шундый ук, әмма күннән кирәк иде», – дип, күн эшләнмәләр остасы Илдус Гайнетдиновка барганын әле дә көлеп искә ала Данияр Хаҗиев. Кайчан да булса үзем дә күн белән эш итәрмен диган уй ике ятып бер төшенә дә керми әле аның ул чагында. Бу – егетнең татар-төрек лицеен тәмамлап, Казан энергетика университетында укып йөргән мәле. Хәер, аның әлеге уку йортын кызыл дипломга тәмамлавына да нибары дүрт кенә ел. Әмма шушы кыска гына вакыт эчендә ул инде билгеле бер даирәдә, төгәлрәк итеп әйткәндә, күнчеләр, кулланма-гамәли сәнгать белән шөгыльләнүчеләр арасында үзен бик талымлы оста итеп танытырга да өлгерде.

ОСТАХАНӘ

КОРАЛ ЭШЛИ, ИР МАКТАЛА

ЭЗЛӘГӘН ТАБА

Егетнең күннән эшләнгән букча-портфельләрен, акча янчыкларын, каешларын күреп: «Энергетика өлкәсендә инженер булып эшләп йөрүче егет бу кадәр эшләр майтарырга каян вакыт таба да кай арада бу һөнәрне шушы дәрәҗәдә үзләштерергә өлгергән соң?» – дип аптыраучылар да юк түгелдер. Барысына да үз тырышлыгы, үҗәтлеге белән ирешә Данияр. Шул ук вакытта моның өчен абыйсы Разимга да рәхмәтле булса кирәк әле ул. Юк, кулыннан тотып күн эшенә өйрәткәне өчен түгел, әлбәттә, ә моннан дүрт ел элек туган көнендә шәп кенә телефон бүләк иткәне өчен… Менә шуннан башлана да инде. Көн дә инстаграмга нәрсәдер «элеп», лайклар җыя башлый Данияр. Фотолар да куеп карый, ләкин күрә – берсенең дә моңа әллә ни исе китми. Кемгә кызык инде синең тормышың диган фикергә килә. Аннары рәсем ясый башлый. Ни дисәң дә, мәктәптә укыганда өч тапкыр сәнгать мәктәбендә укырга омтылып караган кеше бит. Ясап-ясап карый, ләкин үзенә ошамый. Лайклар да сөендерми. Аңлашыла: башкару дәрәҗәсе дә түбән, мәктәптә юк… Шунда Мәскәүдән күн белән эшләүче Антон исемле егетнең эшләнмәләренә тап була. Нәрсәсе белән җәлеп итә – эшләренең башкару дәрәҗәсе югары. Менә шунда үзенең нәрсә эзләгәнен аңлый Данияр. Элемтәгә керә, Антонның үзе белән дә сөйләшә.

– Сине Россиядә бер кеше дә тиешле дәрәҗәдә өйрәтмәячәк, чөнки бездә андый мәктәп юк, – дип, аңа бер-ике сайт тәкъдим итә Мәскәү егете.

– Үземә өйрәнергә кала икән, – ди Данияр.

Эшне азмы-күпме күн, кораллар алудан башлый һәм телефон чехоллары ясарга утыра. Үз-үзенә нык ышанган булса да, уйламаганда гына бик яхшы күн кисәген бозып ташлый. Ярый әле башлаган эше үзе теләгәнчә камил килеп чыга. «Була икән бу!» – ди.

ҖӨЙЛӘРЕ АЕРЫЛЫП ТОРА

Бүген инде аның кулы белән ясалган күн эшләнмәләрнең төре генә дә берничә дистәдән артып китә. Ә башкару осталыгы ягыннан останың кулын күпләр арасыннан танырга мөмкин. Тезелеп киткән «чыршылар» кебек бик наят эшләнгән «Европа җөе» дә, «Сәлам Мәрьям» логотибы да һәм инде сыйфатлы күннәре дә «Мин Даниярныкы» дип кычкырып тора.

Беренче карашка ук аерылып та тормас иде, гадәттә күнчеләр башкачарак төрле җөйләргә өстенлек бирә, икенчедән, тозсызны күзсез дә аера дигәндәй, еш кына полиэстер – тупас җеп белән тегәләр. Даниярда исә һәрвакыт Франциядән кайтартылган иң яхшы җитен җеп булыр.

– Син инде үзеңне иҗатта таптым дип уйлыйсыңмы? Әллә моңа өстәмә кәсеп буларак кына карыйсыңмы? – дим остага.

– Минем, әлбәттә, кәсеп өчен эшли торган әйберләрем дә бар. Аларны автомат рәвештә ясыйм. Андыйларда иҗат дигән нәрсә юк. Алар – көнкүрештә кирәкле, сыйфатлы, матур, чыдам әйберләр. Шул ук вакытта тәмләп эшли торганнары да бар. Алар хәтта өстәлдә ятканда да аерылып тора. Беләм, бу өлкәдә мин әле үз сүземне әйтергә, үз йөземне булдырырга тиеш, чөнки ансыз булмый. Әлегәчә моңа кадәр булган тәҗрибәгә таяндым дип уйлыйм. Эшләгәндә, берсүзсез, берсенә үземнән – бер әйбер, икенчесенә икенче әйбер өстим. Утырсаң, әлбәттә, эшләнә. Миңа бер төрле операцияне берочтан башкару ошый. Бер атна эчендә дүрт-биш портфельне рәттән теккәнем бар. Бер төрле эш эшләгәндә кул күнә, вакыт та янга кала…

Моннан элек «Печән базары»нда башыннан ахырына кадәр кул белән тегелгән, яхшы фурнитуралы бик затлы саквояжын сатып җибәргәнен хәтерлим әле Данияр Хаҗиевның.

– Кеше мондый сыйфатлы әйберне дә күрергә тиеш, – диган иде ул вакытта оста.

Бүген инде аның үзенә дә: «Әйдә мин сиңа өйрәнчек булып килим әле», – диючеләр булса да, гаеп түгел.

– Әгәр дә берәрсе: «Мин сиңа акча түлим, өйрәт әле», – ди икән, монысы – бөтенләй башка әйбер. Кеше һәр нәрсәнең үз бәһасе булуын аңларга тиеш. Бездә моны аңлап бетермиләр. Электәэлектән өйрәнчек булып килгәннәр осталарга. Әйтик, мине балта остасы эше кызыксындырды ди. Моның өчен мин, әлбәттә инде, остазга түләргә яки өйрәнчек буларак аңа бушка эшләргә тиеш. Аның каравы эшкә өйрәнәм бит. Гыйлем ул – гомерлек, – ди Данияр.

Әмма әлегә Данияр Хаҗиевның эш өстәле янында олы кызы – өч яшьлек Мәрьямнән башка берәү дә күренми шикелле. Ә ул әтисе кул юарга киткән арада да аның берәр эшенә үзе белгәнчә «култамгалар» сырлап куярга да мөмкин икән әле.

WORLDSKILLSка ЭШЕ ӘЗЕР

– Эх, менә шуны эшләргә иде, дип ниятләп йөргән, әлегә йөрәк җитмәгән әйберләр юкмы? – дип кызыксынам.

– Аяк киеме тегәсем килә. Мин моңа тотынып карадым. Теләк бар. Ләкин бөтен әйберне бәя хәл итә. Нинди-дер вакыт эчендә безнең халык яхшы әйбердән биздe. Күп кешегә арзан кирәк, матур кирәк, сыйфатлы кирәк. Әмма аларның бөтенесе бер җиргә сыя алмый. Әйтик менә АКШта һәр останың үз бәясе бар. Шул исәптән сәгате 15әр доллар белән бәяләнә торган осталар да. Бүген шулкадәр акчаны түләргә кем әзер бездә? Миңа, мисал өчен, портфель эшләр өчен 16 сәгать вакыт кирәк. Кем 16 сәгатькә 15әр доллар бирергә, ягъни 200 доллар түләргә әзер? Юк. Шуңа да мин аны 100 долларга сатам. Ә эш коралларын, күнне Япониядән яки Европадан кайтартам, – дип, оста үзенең исәп-хисапларын да санап узды.

Моннан элек Корстонда узган «Энҗе» бәйгесендә дә катнаша ул. Оештыручыларның берсе килеп: «Миңа синең әйберләрнең эшләнеше ошый. Бик профессиональ. Ләкин синә беренче урынны бирә алмыйбыз – монда милли бизәкләр юк», – ди. Дөресен генә әйткәндә, тотып торырлык әйберен булмаса, аны бизәк тегеп кенә дә коткарып булмый инде анысы.

Хәер, хәзер инде Данияр Хаҗиев үзе дә теләсә кайсы эш янына килеп, «Бизәге матур, әмма эшләнеше начар. Эшләнеше матур, ләкин күне начар», – диярга мөмкин. Бу, билгеле, аның масаюы да, үзен өстен куюы да түгел. Бары тик япон осталарының, Европа күнчеләренең эшләрен шактый өйрәнүдән һәм эталонның ни икәнен аңлаудан гына килә ул. Ни өчен аларның эшләре яхшы килеп чыгуын ул үзенчә бәяли.

– Беренчедән, аларның эш кораллары яхшы. Бу бик зур плюс, – ди Данияр. – Бервакыт бер бик яхшы танышым – теш табибы Мансур абый Хәйдәршин белән чәй эчеп утырабыз да, «Эш коралы алыр идем, акча юк», – дим. Бу минем һич кенә дә акча соравым түгел иде. Ә ул: «Мә, ни телисең шуны ал, әмма яхшы эш коралы белән эшләргә өйрән», – дип, акча сузды.

Бара торгач, Франциядән күп кенә эш коралы килеп төшә үзенә. Корал эшли, ир мактала, ди халык мәкале. Бәяне эшең матур булган өчен генә куймыйлар шул. Камиллеккә, башкару осталыгына бәйле барысы да. Юкса, бездә ике алымны бергә кушарга өйрәнүгә үк базарга сатарга чыга башлыйлар. Менә шуларны аңлаган күнче буларак, Данияр Хаҗиев башта үзенең башкару техникасын билгеле бер дәрәҗәгә җиткерә. Ни өченме? Булыр-булмас әйберне тәкъдим итү оят булган өчен. Бүген инде Данияр Хаҗиевны заман белән бергә атлаучы инженер-күнче дия алабыз. Өстәлендә 2019 елда узачак WORLDSKILLS – эшче һөнәрләре чемпионатында эш кораллары салыначак букча яткан оста турында тагын ни әйтәсең? Булдыра!

Расиха ФӘИЗОВА.

Милли ашлар: мордва кухнясы

АШ БУЛСЫН!

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

МОРДВАЛАР – КУНАКЧЫЛ ХАЛЫК

Бу юлы кунакта булу миңа аеруча ошады. Мордвалар татарлар кебек бик кунакчыл халык икән. Милли ризыкларыгыз белән танышасы килә дигәч, Наталья Сабитова безне өенә кунакка чакырды һәм, мордва җырларын җырлый-җырлый, берьюлы берничә милли ризык пешереп күрсәтте.

Мордва халкының кухнясын, нигездә, ит һәм балык ризыклары тәшкил итә. Борынгы вакытлардан ук алар аучылык белән шөгыльләнгән. Елга буйларында яшәгәч, табында гел балык булган. Мордва кухнясында иң популяр ашлар – балык окрошкасы, тавык итеннән щи, цебярь шурьба, ягъни уха һәм селянка. Аш-су остасы белән без дә селянка пешердек. Ул зур бәйрәмнәр вакытында һәм туйның икенче көнендә пешерелә икән. Селянка яңа суйган терлек итеннән, бавыр, йөрәк, үпкәсеннән әзерләнә. Өч литр суга 200 гр бавыр, 200 гр ит, 200 гр үпкә, 100 гр йөрәк салып кайнатырга куйдык. Итне эре кисәкләргә бүлдек. Ит пешеп чыккач, шулпага суган һәм саламлап туралган бәрәңге, пешеп чыгар алдыннан помидор, петрушка турап салдык.

Чәй янына исә суронь пачалксеть пешердек, безнеңчә ул тары коймагы була. 200 гр тарыны егерме минутка сөткә салып торабыз. Аңа ике күкәй, тоз һәм шикәр комы кушабыз. 100 гр он салып болгатабыз да кайнар табада майда пешерәбез.

Аш-су остасының сүзләренә караганда, Мордовия, Пенза, Саранск кафе-рестораннарында офтонь лапат дигән ризык бик популяр икән. Тәрҗемәсе – аю тәпие була.

– Риваятьләр буенча, элек өйләнер алдыннан егетләр үзләренең чын ир икәнлекләрен аю үтереп расларга тиеш булган. Алай гына да түгел, аюның тәпиен кыздырып, аны кызга бүләк итәргә дә кирәк. Авылның бер ябык кына, кечкенә генә егетенең моңа көче җитмәгәч, аңа әнисе бозауның үпкәсен иттарткыч аша чыгарып пешерә, кара ипине аю тырнаклары кебек итеп кисеп бирә. Хәзер инде аю тәпие сыер итеннән әзерләнә. Күкәй, тәмләткечләр, суган салынган фарш кәтлит рәвешендә пешә дә өстенә, аю тәпие сыман, сохари куялар, – дип сөйли ул.

Туйларга мордвалар зур итеп махсус лукш пирогы пешерә. Ул безнең гөбәдия кебек баллы һәм катлы пирог икән. Эчлеккә кара җимеш, йөзем, күрәгә салына.

– Аны кәләш йортына булачак каенанасы алып килә. Пирогны өчкә бүләләр. Бер өлеше кыз өендә кала. Бер өлешен үзләренә кире алып кайтып китәләр, ә калган бер өлешен кызны киендергән йортка алып баралар. Мәҗүсилектән калган йолалар буенча, кәләшне бездә башка йортта киендерәләр. Ул йорт авылның югары урамында яки югарыда урнашкан өйдә булырга тиеш. Киленне, сездәге кебек, чишмәгә суга алып барып сыныйлар. Ул суын мөмкин кадәр чайкалдырмыйча алып кайтырга тиеш. Суы никадәр азрак түгелә – тормышы шуның кадәр яхшырак була дигән ырым бар. Мәҗүсилек дигәннән, бездә мунчадан чыккач, мунча иясенә рәхмәт әйтәләр. Урманнан чыккач та, Табигать-анага рәхмәт әйтәбез, – ди Наталья Михайловна.

Эчемлекләргә килгәндә, мордва кухнясында алар шулай ук зур урын алып тора. Иң киң таралган эчемлек – поза, аны икенче төрле квас дип тә әйтергә була. Ул шикәр чөгендереннән, арыш яки арпа онынннан әзерләнә.

Мордваларда тавык йомыркасы уңдырышлылык символы булып санала. Троицада да йомырка тәбәсе әзерлиләр икән. Кунакларга да, хөрмәт йөзеннән, күкәй пешерелә. Әмма аның үз хикмәте бар. Наталья Михайловна да без килешкә пешереп куйган иде аларны.

– Йомырканы минем әни авыл мичендә пешерә. Чуен чүлмәккә тутыра да ул шунда көне буе әкрен генә утыра. Мин исә газ миченнән генә файдаландым, – ди ул.

Алты сәгать буе пешкән йомырканың агы да коңгырт төскә кергән иде. Тәме дә үзенчәлекле, ашавы да күңелле. Сөтне дә газ мичендә чуен чүлмәктә махсус озаклап кайнаткан иде хуҗабикә. Чәе исә төрле үләннәр салып кайнатылган булып чыкты.

«ГӨБӘДИЯ ЯРАТАМ»

Наталья тумышы белән Чувашиядәге Порецкий районының Мордовия белән чиктәш булган Алвеле (Напольное) авылыннан. Дүрт ел элек кенә Казанга килгән. Спортта да, җыр-биюдә дә активлыгын күреп, мордва милли-мәдәни автономиясе рәисе урынбасары итеп куйганнар. Аш-суга осталыгының сере дә ачылды: сигез ел кафе-ресторааннарда шеф-повар булып эшләгән икән. Иң кызыгы шунда – Казанга килгән туристлар өчен татар кухнясы буенча осталык дәресләре уздыра ул. Токмачын да кисә, гөбәдия, өчпочмак, чәк-чәген дә пешерә.

– Мин бер урында торырга яратмыйм. Нәрсә белән дә булса гел кызыксынып торам. Татар ризыклары белән башта интернет аша таныштым. Монда килгәч, кафега эшкә урнаштым. Директорыбыз бервакыт туристларга мастер-класс күрсәтү идеясен әйтте. Мин ризалаштым. Пешерергә генә түгел, сөйләргә дә яратам мин, – ди ул.

Гөбәдияне тәмле итеп пешерү серләрен дә шул вакытта ача.

– Аның корты күп булырга, калын итеп җәелергә тиеш. Ул баллы һәм майлы булсын. Аңа бармак белән басып карагач, бармакта мае калырга тиеш. Дөгесен менә азрак салыгыз, – ди аш-су остасы.

Үзенең дә яраткан ризыгы гөбәдия икән.

Татар кухнясын үз итүенең тагын бер сере – хәләл җефете татар кешесе. Өйдә татарча да, мордвача да, русча да сөйләшәләр. Кызлары өч телне дә яхшы белә.

– Тел ул гаиләдә саклана. Без кызыбызга татар һәм мордва телләренә өйрәнүне мәҗбүриләп куймадык. Һәр сүзнең татарчасын да, мордвачасын да кабатлап, аңарда кызыксыну уяттык. Авылга әбисе янына кайткач, ул аның белән рәхәтләнеп мордвача сөйләшә, әтисе белән татарча аралашалар. Безнең өйдә ике тел дә бертигез дәрәҗәдә, икесенә дә ихтирам белән карыйбыз, – ди Наталья Михайловна.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Язманы әзерләүдә булышкан өчен, Татарстан халыклары дуслыгы йортының мордва милли-мәдәни автономиясенә рәхмәтебезне җиткерәбез.

«Бер пластик шешәне эшкәртеп, без сезнең белән 3 литр чишмә суын, 15 кв м уңдырышлы җирне һәм ике буын урман җәнлекләрен саклап калабыз». Әлеге сүзләр Идел буе районы йортлары ишегалларына урнаштырылган контейнерларга язылып куелган. Анда күрсәтелгән телефон номерын җыеп, без әлеге проектның авторы белән танышырга булдык. Богдан Сабуров бу эшкә дүрт ай элек кенә тотынган һәм ул фәкать пластик шешәләр җыю белән шөгыльләнә. Шушы кыска гына вакыт эчендә аның проекты чиста керем дә китерә башлаган.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

2016 ел мәгълүматлары буенча, Татарстанда каты көнкүреш калдыкларының күләме 1 миллион 573 мең тонна булган. 2010 елдан аның күләме якынча 370 мең тоннага арткан. Хәзерге вакытта республика күләмендә чүпне аерым җыю өчен 200гә якын контейнер, пластик шешәләр җыю өчен берничә йөз контейнер һәм терекөмешле лампа һәм батарея кебек куркыныч каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен 100гә якын контейнер исәпләнә. Республикада зур предприятиеләрдән чүп-чар җыю белән шөгыльләнүче унга якын эре компания бар. Ә халыктан икенчел чимал җыючы шәхси компанияләр тагын да күбрәк. Икенчел чималның иң популяр төрләре – катыргы һәм полиэтилен. Әлеге исемлектә шулай ук пластик, металл һәм пыяла да бар. Әгәр халыктан җыелган көнкүреш калдыкларында икенчел чимал 10-13 процент чамасы тәшкил итсә, оешмаларныкында әлеге күрсәткеч, теге яки бу компаниянең эшчәнлек төренә карап, 40-50 процентка кадәр җитә.

ЧҮПТӘН АКЧА ЭШЛӘҮ

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Әлеге идея узган елның август аенда туган иде. Берәр яңа эш башлыйсы килде. Баштарак пекарня ачарга уйладым. Аннары пластик шешә эшкәртү предприятиесе турындагы идея калкып чыкты. Әмма бизнес-план төзеп исәпләп караганнан соң, пластик шешәләрне җыю, аны эшкәртүгә караганда, күпкә отышлырак булуы ачыкланды. Чимал булмаса, предприятие тукталып торачак дигән сүз. Шуңа да башта аны җыю эшен башларга кирәк дигән фикергә килдек. Бу өлкәдә көндәшләр дә алай артык күп түгел, – ди «Эко-приоритет» компаниясе генераль директоры Богдан Сабуров.

Шешәләрне җыеп, сортларга бүләләр һәм пресслап эшкәртүгә җибәрәләр. Аларны контейнерлардан җыеп алу белән өч кешелек бригада шөгыльләнә. Чүп атнага бер тапкыр алына. Аена барлыгы 15-17 тонна җыела. Чүптән дә акча эшләп була дигәннәре хак икән. «Аена чиста керем – уртача 150 мең сум», – ди Богдан.

Аның сүзләренчә, шәһәр халкы чүпне аерып җыюга акрынлап күнегә башлаган. Бу – аларның экология турында кайгыртуы, дигән фикердә Богдан.

– Контейнерда күрсәтелгән телефон номерына шалтыратып, рәхмәтләр дә җиткерәләр. Аны күреп китүчеләр үзләренең йортлары янына да контейнер куюыбызны сорыйлар. Макулатура, пыяла өчен дә куелса, яхшы булыр иде, диләр. Элек контейнерлар ике атна эчендә тулса, хәзер моңа бер атна да җитә, – ди ул.

– Йорт ишегалларына контейнерларны куюга идарәче компанияләр ничек карый? – дип кызыксынам мин аннан.

– Коммерцияле торак милекчеләре ширкәтләре безнең эшне аеруча хуплый. Тагын 300 контейнер урнаштыру өчен урыннар билгеләп куйдык. Без аларның эшләрен дә киметәбез бит.

Шәһәр буйлап, дөресрәге, Идел буе районында алар 350 контейнер урнаштырган. Киләчәктә аларның санын 3 меңгә җиткерергә уйлыйлар.

– Ничегрәк эшләп китәрбез икән дип, баштарак 50 контейнер куеп караган идек, проект үзен бик тиз аклап, керемә дә күренә башлагач, аларның санын арттырырга булдык, – ди әңгәмәдәшем.

«Эко-приоритет» компаниясе хәйрия проекты турында да уйлана башлаган. Алар шешә капкачларын җыя башламакчылар. Мондый проект Испания, Европа илләрендә, Мәскәүдә дә бар ди. Аның өчен кибетләрдә, спорт залларында һәм башка кеше күп була торган урыннарда махсус савытлар урнаштырып, аларны эшкәртүгә тапшырган акчаны компания хәйрия максатларында кулланырга ниятли.

– Берьюлы ике куян койрыгын тоту була бу – табигать турында да кайгыртабыз, ярдәмгә мохтаҗларга да булышачакбыз, – ди идея авторы.

Кыскасы, без сатып алган судан бушаган гап-гади шешә иртәгә футболка яки чәйнеккә әверелергә мөмкин. Могҗиза түгелме ни бу?!

ПЛАСТИК ТУРЫНДА КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР

- Пластик тулысынча таралып бетсен өчен **500 ел** кирәк.
- Пластик калдыкларның **40 процентын** пластик шешәләр тәшкил итә.
- Су өчен түләгәндә сез бәянең **90 процентын** пластик шешә өчен түлисез.
- Алга киткән илләрдә яшәүчеләр елына уртача **150** шешә су сатып ала.
- Бер миллиард шешә җитештерү өчен **24 миллион** галлон нефть кирәк.
- Олы кеше өчен бер пиджак тегәргә **25** эшкәртелгән шешә җитә.
- Ел әйләнәсендә дөньяда **13 миллиард** пластик шешә җитештерелә.
- Америкада **1600** предприятие пластик эшкәртү белән шөгыльләнә.
- Халыкның **90 проценты** полиэтилен пакетларны берничә тапкыр куллана.
- Австралия, Кытай, Австрия, Бангладеш, Ирландиядә пластик шешә куллану тыелган.



ИСКЕ ИДЕ, ЯҢА БУЛДЫ

Иске пластик шешәләрне эшкәрткәннән соң, алардан бик күп әйбер эшләргә була:

асфальт (Голландиядә кайбер юлларны эшләгәндә, эшкәртелгән пластикны балалар конструкциясе кебек җыялар)

кием-салым (аеруча спорт костюмнары)

йорт җиһазы

велосипед (аның рамын эшләргә 200 шешә китә)

степлер, ручкалар өчен контейнер, линейка, рюкзак

МӘЛЕНӘ – ӘМӘЛЕ

Көнкүрештә куллану өчен, пластик шешәдән ныклы җепләр, баулар да эшләп була. Ике литрлы шешәдән 0,5 см киңлектәге 10 метр җеп чыга. Ул помидор һәм кыярларны бәйләп куярга бик кулай. Кемдер пластик җептән кечкенә паласлар үрә, кемдер кер бавы буларак куллана, себерке ясаучылар, кәрҗин, сумка үреп эшләүчеләр дә бар. Җеп ясар өчен, шешәнең өске һәм аскы өлешен кисеп алыгыз да маникюр кайчы белән спираль буенча кисеп барыгыз.

Дөнья нәрсәгә эләгеп тора?

Үтеп барышлый

Равил САБЫР

Кызганыч, яз килде. Ә, юк! Дөрес әйтмим икән лә, яз гел шулай килеп торсын инде ул, ә менә кышның узып китүе кызганыч. Яратам мин елның шул фасылын, үзем кышын тугангадыр инде...

Мартта туасы бала булганмын югыйсә. Ашыга-ашыга, җиде айлык булып, гыйнварда бу якты дөньяга килгәнмен. Шуңа Сабырдыр инде. Әнинең сөйләүләре буенча, туган авылы Сәеткә берничә көнгә кунакка кайткан булган ул. Авырый башлагач, юл аркылы торучы күршесе, ахирәте белән Минзәләгә барырга дип «попутка»га чыкканнар. Хәзер генә ул машиналар тыз да быз чабып тора, ә бу бит 1974 елның гыйнвары. Чаллы белән Минзәлә арасындагы олы юлга кадәр җиде-сигез чакрым ара бар. Район үзәгенә кадәр гомумән 30 тирәсе. Ярый инде алай да аларның һич минем бәхетемә ГАЗ-51 йөк машинасы очраган, аның йөртүчесе бик шәфкатьле һәм игелекле абзыкай булып чыккан, әнине бүлнискә илтеп куйган.

Икенче көнне әти килгән. Шулай-шулай дип аңлатканнар, хатының авырый башлады да Минзәләгә китте, бүлнискә, дигәннәр. Әти дә киткән инде Минзәләгә әнине эзләп. Ул чакта Үзәк район хастаханәсе бинасы булмаган әле, теш бүлнисе аерым бер агач йортта, күзнеке – икенче бер бинада, травматология – өченчесендә һ.б. Йөреп чыккан әти барысын да, әни берсендә дә юк икән. «Кичә роддомда бер хатын малай тапты, шунда бар син», – дигәннәр әтигә. «Юк инде, нишләп анда булсын, ике айдан гына бәбәйләргә тиеш бит әле ул?!» – дигән әти. Алай да, киткән инде бала тудыру йортына. Килсә, шәфкать туташлары шаккатырганнар моны: «Котлыйбыз! Улыгыз туды», – дигәннәр.

Берничә көннән алып кайтканнар мине. «Тире белән сөяк кенә идең инде, улым, ат башы хәтле борының гына тырпаеп тора иде», – дип сөйли әни. Аның олы апаларының берсе, мине күргәч: «Юк, яшәрдәй бала түгел бу, барыбер үлә! «Улым» дип әйтеп иялəшмә, үзеңә аннары авыр булыр!» – дигән. Бәлки бүген бу сүзләр кискенрәк тә яңгырый торгандыр, тик ул апа – үз гомерендә бик күп балаларның авырулардан, ачлыктан үлгәннәрен күргән кеше, шуңа күрә аңа үпкәләп тә, аны артык гаепләп тә булмый. Аны гаепләгән кеше дә юк, киресенчә, җор телләрәк туганнар ара-тирә төрттерергә яраталар: «Менә син үлә дигән Равил ике метрлы булып үсте», – диләр.

...Начар гадәтем бар: бер нәрсә турында сөйли башлыйм да гел икенче якка каерып алып китәм. Ркаил әйткән иде берсендә: «Син бит сүз стихиясе белән язасың, Фолкнер кебек», – дип.

Сүз башым бит кыш иде...

Яратам шул мин кышны! Рәхәт бит, бөтен җир ап-ак, чип-чиста! Суык, сине сынарга теләгәндәй, бит очларыңнан чеметкәли, кул-аякларыңны туңдырмакчы була, ә син бирешмисең! Буран котырганда урамда йөрү – үзе бер мәҗара. Якын-тирәдә хаос, ә син аңа игътибар да бирмичә үз юлыңнан барасың. Ә аяк астындагы карның шыгырт-шыгырт килгәне үзе бер музыка кебек бит! Менә күз алдына китерегез: әйтик, кар яумады ди?..

Яумады да ул 90нчы елда. Казан университетының беренче курсында укыган чагым. Декабрь азагы җитте – бер бөртек кар төшкәне юк. Урамнан трамвай узса, артыннан кызыл көрән төстәге тузан уйнап кала, рельслар тутыгып ята чөнки. Шундый шыксыз, ямьсез иде ул кышта Казан урамнары. Меңьеллыкка, Универсиадага дип төзү-төзекләндерүләр юк бит әле ул чакта, Татарстан башкаласы ярым җимерек хәлдә ята иде. Өстәвенә миңа – яңа гына авылдан килгән, шәһәргә әле күнекмәгән яшүсмергә – бу шөкәтсезлек бигрәк тә нык тәэсир иткәндер, күрәсең.

31 декабрьдә кичке уннарда гына яуды кар ул елны. Яңа ел килеп җитәргә ике сәгать кала! Авылга кайткан идем мин – анда да кар юк иде. Әйтәм бит, шул кичке уннар тирәсендә клубка бара идем, кинәт кар ява башлады. Андый эре кар бөртекләрен минем аңа кадәр дә күргән юк иде, аннан соң да күрмәдем! Ябалак-ябалак кар ява, диләр андый чакта. Хәтерлисезме, без мәктәптә укыганда класс түшәмнәренә ак җепләр тарттырып, шуларга мамыклар тезеп бизи торган идек? Әйтерсең лә Кыш бабай бөтен дөньядан шул мамыкларны җыеп алган да: «Бәйрәмдә моңаеп йөрмәсеннәр болар», – дип, күктән яудырган сыман иде. Менә хәзер дә, шул чакларны искә төшереп язып утырганда да, күңелгә рәхәт ничектер. Бик бәхетле итеп хис иткән идем мин үземне шул мизгелләрдә!

Ә тагын Рәшит абый Гәрәй искә килеп төште. Минзәлә ягында туып-үскән, иҗат иткән бик нечкә күңелле, талантлы шагыйрь. Шундый булмасаң, менә болай гади һәм шул ук вакытта моңлы, сагышлы итеп язып буламы?

Кыр казлары оча җылы якка,
Күз күрмәгән ерак җирләргә.
Тын һавада моңсу тавышлары
Сәлам булып җилдә тирбәлә.

Нигә ул искә төштеме? Мәктәптә укыган чакта очрашуга килгән иде ул берсендә. Алты дәрес укып чыкканнан соң шигырь кайгысы калмый бала-чаганың, тизрәк өйгә кайтып таясы килә. Тик Рәшит абый беренче секундлардан ук безнең игътибарны үзенә җәлеп итә алды. «Балалар, сезнең яңгыр астында калганыгыз бармы?» – дип сорады ул. Бар, бар, диешәбез. «Рәхәтме?» – диде ул. Юк, юк, дибез. «Ә мин яратам яңгыр яуганда урамда, кырларда йөрергә...» – ди шагыйрь абый. Без, авызларыбызны ачып, аны тыңлый башладык. Очрашу беткәнче ябылмады бугай ул авызлар...

Иҗат кешесе шундый сәер инде, нишләтәсең? Берсенә яңгыр астында чыланып йөрү рәхәт, икенчесе кышны ярата, буранда каядыр барганыннан да фәлсәфә чыгарырга тырыша, бер нәрсә турында сөйли башлый да бөтенләй башка әйберләр белән тәмамлап куярга мөмкин. Бер уйлаганда, без иҗат кешеләре бик кечкенә масштабтагы эш башкарган кебек. Әйтик, чыгарды ди берәр шагыйрь соңгы биш-алты елда язган иң яхшы шигырьләрен туплап берәр җыентык. Тиражы 1000 данә булыр инде. Ә менә футболда, әйтик, бер уенга 20дән алып 50 меңгә кадәр кеше җыелырга мөмкин. 50 мең тапкыр күбрәк!!! Юк, чыннан да, иҗат кешеләренә – шагыйрьләргә, язучыларга, журналистларга, артистларга, режиссерларга, рәссамнарга, композиторларга һ.б. – бернигә дә йогынты ясамый торган, берни дә хәл итми торган микроб дип карарга була... Ләкин шушы азсанлы кешеләрдә шул кадәр көчле рух, шул кадәр чиста, гаҗәеп гүзәл илаһи энергия, шул кадәр үз-үзен аямас хәлгә җитәрлек фидакарьлек бар ки, хәтта мин кайчагында дөнья әлегә кадәр мәтәлеп китмәгән икән, ул беренче чиратта иҗат кешеләренең әнә шул сәерлекләренә эләгеп тора дип уйлап куям...

Әлмәт,
2017 ел, март.

ҮЗЕМ КҮРДЕМ

Песиләрнең дә үз кафесы бар

«Котокафе»лар турында беренче ишетүем. Баксаң, Уфада, Казанда песиләр кафесына йөрү бик популяр икән. Карап торышка гади чәйханә. Аермасы – даими яшәүчеләре – песиләрендә.

Мондый кафеларның тарихы Япониягә барып тоташа. Кояш чыгышы илендә элек тә, хәзер дә андый кафелар урам саен икән. Тик анда башкачарак: кафега килеп, песиләрне күзәтеп утырырга гына була. Ә бездә исә яратасы килгән песине кулыңа аласың, иркәлисең, аның белән уйныйсың, бик ошаса, өеңә дә алып китә аласың.

Уфадагы кафе «Котейная» дип атала. Песиләргә битараф булмаган уфалылар әлеге урынны яхшы белә. Кафе бинасы мәчеләр өчен махсус җиһазландырылган. Баскычлар, киштәләр, тырнак чарлагычлар, кечкенә йортлар һ.б. бар биредә. Иң мөһиме – дүрт аяклы дусларыбызга ямансу булмасын. Песиләргә карап, барлык мәшәкатьләреңне онытырга, уңай энергия тупларга була, дип саный әлеге бинаның хуҗасы Евгений.

– Төүге тапкыр мондый кафеда Таиландта булдык. Сәяхәтнең онытылмас мизгеле буларак һаман да хәтердә саклана. Бары тик токымлы песиләр иде анда. Гомумән, Азия илләрендә песи культы аеруча киң таралган. Ул вакытта бездә Санкт-Петербургта гына песиләр кафесы бар иде. Үзем – Мәскәүдән, хатыным – Уфадан. Әлбәттә, Мәскәү шартларында теләкне тормышка ашыру бик кыйммәт булыр иде, шунлыктан Уфага тукталдык. Без планнар корып йөргәндә, андый кафены Казанда да ачтылар. Казан егетләре безгә үзләренең кыйммәтле киңәшләрен дә бирделәр, – ди ул.

Песиләр кафесына кемнәр йөри, дисезме? Монда бизнесменнарны, эше компьютер белән бәйле булганнарны еш очратасың. Ноутбуклары белән килеп утыралар да песиләр белән бергәләп эшлиләр. Өйгә песи алырга теләмәгән әти-әни балалары белән килә. Алар – даими клиентлар. Биредә балалар туган көннәрен уздырырга ярата. Мәҗлес вакытында кафе башка кунаклар өчен вакытлыча ябылып та тора.

Бу кафега, әлбәттә, песине үлеп яратучылар гына килә. Ә бит күпләрнең аларны өйдә тотарга мөмкинлеге юк. Хәтта өйдә песиләре булганнар да килә икән. Өйдә берне кочаклап утырганчы, берьюлы 20 песи компаниясендә булу башка бит!

– Өемдә ике песием бар. Аларны бик яратам! Тик шулай да кафе атмосферасы башкача. Песиләрне күзәтәсең, холыкларын өйрәнәсең. Бу проект керем өчен эшләнмәгән. Мондый социаль проектта әлеге максатның булуы бөтенләй дә мөмкин түгел. Песи урамда түгел, ә йортта яшәргә тиеш. Ә йортсыз песиләрне без үзебезгә алабыз. Монда аларны беркем дә рәнҗетми, аларны ашаталар, иркәлиләр, атна саен ветеринар тикшеренүе үткәрәләр. Өстәвенә, аларның хуҗалы булу мөмкинлеге бар, – ди Евгений.

Кураторлар белән җитди килешү төзеп, песине өйгә алырга да була. Тик иң беренче чиратта алар җан иясенең ышанычлы кулларга эләгәсенә тулысынча ышанырга тиеш. Соңыннан песинең яшәеше турында фотоотчет җибәреп, кафе җитәкчеләре белән бәйләнештә булырга кирәк. Бу күпмедер вакыт узганнан соң песидән котылу чарасы күрмәс өчен эшләнә. Ярты ел эчендә 30 песи үз хуҗасын табып өлгергән.

«Песи терапиясе» стрессларга каршы торырга яхшы ярдәм итә. Песиләр яман чирләрдән саклый дигән гыйльми тикшеренүләрнең нәтиҗәсе дә бар. Өйдә песи тотканнар, песи кафесына еш йөргәннәр бу хакта яхшы белә.

Азалия ИСМӘГЫЙЛЕВА.

ӘТИЕБЕЗНЕҢ ИҢ ЗУР БАЙЛЫГЫ БЕЗ ИДЕК

Әтием Билсур Зәкиев үлгәндә, миңа 19 яшь иде. Ул көнгә кадәр мин дөнья гел шатлыклардан, рәхәт мизгелләрдән генә тора, кешеләр барысы да яхшы күңелле, без гел шулай тату һәм бәхетле яшәячәкбез дип уйлый идем.

Шул көнгә кадәр мин әти белән әни мәңгелек дип яшәгәнмен. Дөресрәге, мин әле үлем белән очрашмаган бик бәхетле бер сабый идем. Әти алдагы көнне һәр бәйгегә үз фикерен белдереп, һәр уенны шаян сүзе белән шәрехләп, һәр катнашучыны дәртләндереп, һәр җиңүчене котлап, шау-гөр итеп Сабан туен алып барды. Ә иртәгесен, мунча керергә чыгып барганда, баскыч төбендә җан бирде. 57 яше дә тулмаган иде. «Йөрәк» диделәр…

Әти үлгәнгә быел 19 ел була. Гомеремнең нәкъ яртысын мин инде әтисез яшәгәнмен. Кайчакларда миңа әтине сагыну газабы гасырларга сузылгандыр шикелле тоела. Үз күзләрем белән мәетен күреп, аякларын кочып, шашып еласам да, әти бер кайтыр шикелле. Шушы еллар буе мин аны эзлим, көтәм һәм көтәчәкмен. Әгәр дә бер могҗиза булып, әтиле вакытыңны ярты көнгә генә кайтарабыз дисәләр, кайсы мизгелләрне сайлар идем икән? Урманда йөргән чакнымы? Әти безне табигатькә, урман-кырларга гашыйк итте, җиләк, гөмбә җыярга өйрәтте. Ул авылдагы барлык куаклык, елга, урманның исемен, тарихын, анда нәрсә үскәнен, алай гына да түгел, һәр кырмыска оясын белә иде.

…Шау-гөр килеп үстек без. Кичләрен көлешә-көлешә өстәл уеннары уйнадык, дәрес өйрәндек… Китапка мәхәббәт тә – әтидән. Гаҗәеп акыллы, тирән фикерле, укымышлы шәхес иде ул. Укуның, белемнең кирәклеген үз үрнәгендә төшендерде. Барыбыз да мәктәпне дә, югары уку йортларын да яхшы билгеләргә тәмамладык – әтинең рухына тап төшермәдек.

Әти безне кешеләрне яратырга өйрәтте. Үзе авылны, аның кешеләрен бик яратты, гомере буе алар мәнфәгатен кайгыртты. 25 ел колхозны җитәкләде – бөтен эшләгәне, уйлаганы, кылганы авылны үстерү, кешеләргә яхшылык эшләү, тормыш шартларын яхшырту булды. Күпме үзгәрешләр кичерде ул чорда авыл. «Авыл урамының уртасыннан нык басып, горур атлап йөри аласыз – мин сез оялырлык бер эш тә кылмадым», – дия иде ул. Чынлап та, авылдашлар һәрвакыт әтинең игелекле эшләрен сагынып сөйлиләр. Әти тарихчы да, киңәшче дә, ярдәмче дә иде. Беркайчан да үзен, гаиләсен кешеләрдән өстен куймады. Җитәкче балалары буларак без бер өстенлек тә кичермәдек, кеше белән рәттән печәнен дә чаптык, чөгендерен дә утадык, күп итеп мал-туар, кош-корт та асрадык. Әтидән безгә фатирлар да, йортлар да, алтын-көмешләр дә калмады. Әтинең иң зур байлыгы без – биш баласы идек. Шуңа да һәрберебез әти сызган юлдан атларга тырышабыз. Кешеләргә көчебездән килгәнчә игелек эшләргә, авылыбыз үсешенә өлеш кертергә омтылабыз. Бүгенге көндә безнең бишебез дә – тормышта үз урыннарын тапкан шәхесләр, абруйлы хезмәткәрләр, матур гаиләле әти-әниләр икән, боларның барысы да – әти-әни тәрбиясе, тырышлыгы, үрнәге.

Әтине кайтарып булса, мин аны кайнар йөрәкле, олы җанлы бабаларын рәсемнән генә күреп белгән оныклары белән очраштырыр идем. Шөкер, аларда да әти чалымнары бар… Үзебез турында сөйләп тормас идем, чөнки беләм: әти безне оҗмах түрләреннән гел күзәтеп тора. Гадәттә, ниндидер сөенечле вакыйга алдыннан төшкә керә.

Еллар уза, ләкин алар хәтердән – әтинең яшькелт-зәңгәр күзләрендәге очкыннарны да, колактан – яңгыравыклы көлүен дә, учлардагы әти кулларының җылысын да – берсен дә җуя алмый. Җандагы чиксез ярату һәм сагыну яшәтә аларны. Туган йортта әти урыны, әти бүлмәсе, әти чүкече дигән төшенчәләр яши. Эш коралларын әти өйрәткән урынга куябыз. Яшел күлмәгеннән әле дә әти исе килә. Әти гел янәшәбездә!

Руфия МИФТАХОВА,
Балтач районы,
Арбор авылы.

Бу көйләрдә кайтмый калганнарның хакы бар…

Үрнәк әтиләр арасында минем әтием дә бик хаклы урын алачак. Әтием Биктимер Солтангалиев Минзәлә районының Әтрәкле авылында туган.

Башлангыч белемен – туган авылында, сигезьеллыкны күрше Татар Мөшегесендә алган. Аннары Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумында агроном һөнәрен үзләштерә. Гаиләдә әтием – иң өлкән бала. Аның кыз һәм ир туганнары бар. Әбием белән бабам аларны гаиләдә бер-берсен ихтирам итәргә, авыр чакта булышырга, башлаган эшләрен һәрвакыт ахырга кадәр җиткерергә өйрәтеп үстергән. Олыларны – олы, кечеләрне кече итү дә балачактан салынган.

Әтием армиягә китәр вакыт җиткән көннәрдә Әфганстанда сугыш уты кабына. Татарстаннан чакырылган тугыз меңнән артык солдат һәм офицер Әфганстан җирендә барган сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Алар арасында «һәр егет армия хезмәтен үтәргә тиеш», – дип фикер йөрткән Биктимер Солтангалиев тә була.

1984-1986 еллар була бу. Әтием Герат провинциясе тирәсендә хезмәт итә. Солдатлар ташлар актарып, үзләре яшәрлек землянкалар төзеп, тау башына урнашалар. Үзләре белән Мухтар исемле эт тә була. «Өйрәтелгән бик акыллы эт иде ул», – дип сөйли әтием дүрт аяклы дусты турында. Иптәшләре белән дә бик дус булып, соңгы ризыкларын, суларын бүлешкәннәр алар. Ул елларны әтием бик искә алырга яратмый.

– Әфганстан – бик матур, ташлы ил. Авыллары артык зур түгел, өйләре балчыктан. Анда көндез бик эссе, ә кичләрен бик суык. Кышын кар юк, ләкин җиле салкын. Шулай да без булганда, 13 елга беренче тапкыр кар яуды, – дип сөйләгәне истә.

«Армиягә киткән бер генә солдат та сугышка эләкмәсен иде», – дип тели ул. Әти-әни борчылып тормасын дип, үзе дә аларга яхшы хәбәрләр генә җиткереп торырга тырышкан. Шул елларда бергә хезмәт иткән дуслары белән әтием әле дә аралашып яши. Андый дуслык гомерлек була икән.

Әй син, хәтер, гомер язларына
Безнең яшьлекләрне чакырып ал!
Җырлыйк әле, безнең бу көйләрдә
Кайтмый калганнарның хакы бар!

«Бу җыр Әфган сугышында катнашканнарга багышлап язылган», – ди әтием.

Шушы кадәр мәхшәр эчендә булып кайтса да, ул – йомшак күңелле, оптимист кеше. Аның янәшәсендә кыенлыклар да җиңел генә үтеп китә. Ул бик ярдәмчел дә. Ярдәм сорап килгән берәүне дә кире борып җибәргәне юк. Үзебезнең авыл кызы – әнием Илүзә белән кавышып, алар ике кызга – апам Миләүшәгә һәм миңа гомер биргәннәр. Без аларны бик яратабыз.

Ләйсән СОЛТАНГАЛИЕВА,
Минзәлә районы.

Ятимлекне сизмәдем

«Шәһри Казан» газетасында «Әти хакы» дигән конкурс баруын белгәч, бик дулкынландым.

Минем дә олы йөрәкле әтием турында язасым килде. Мәктәптә укыганда бу хакта язарга курка идем. Ни өчен – үзем дә аңламыйм. Үзенең улы түгеллегемне белә күрмәсен дип куркудан булдымы икән ул. Ә бит ул моны белә торып, мине үз улы итеп тәрбияләгәнне үскәч кенә аңладым. Дүрт яшем тулып киткәч, миңа авыл кешеләре: «Үз әтиең килдеме? Әтиеңне сагындыңмы?» – кебек сәер сораулар бирә башлады. Мин бу ят кешеләрнең ни әйтергә теләгәннәрен берсен дә аңламадым, чөнки бу вакытта мин Филарис әтиемне үз итеп өлгергән идем инде. Биш яшем тулгач, әнием миңа әтиемнең үземнеке түгеллеген аңлатты. Ә мин, бу сүзләрне ишеткәч, нәни кулларым белән: «Тс-с-с әти ишетмәсен», – дип пышылдап дәшкәнмен. Әтием беркайчан да миңа кул күтәрмәде, читкә этәрмәде. Гаепле эш эшләсәм, «Шулай ярыймы соң, улым?» – дип кенә куя иде. Ә әни шелтәләде. Әтием, мине яклап: «Бүтән болай эшләмә!» – дип аңлата иде. Кыш җиткәч, Кыш бабайга рәсемнәр ясый идем дә, әтием аларны эшенә алып китеп, стенага элеп куя. Аннары Кыш бабай бүләк биреп җибәрә иде. Кечкенә чакта урамга чыккач, әти иңнәренә утырта. Менә монысы инде әйтеп бетергесез рәхәт нәрсә. Мин тау шуарга яраттым. Әтием гел минем белән шуды. Аның да шуасы килә дип уйлый идем. Үзе әйтте: мине имгәтә күрмәсеннәр дип шуган икән. Минем балачагым Себердә рәхәт үтте дип авыз тутырып әйтә алам. Әти-әни кочагында ярату хисләренә коенып яшәдем һәм үстем. Миңа ике яшь вакытта әни белән әти шунда киткән булган.

Аннары туган ягыбыз Актанышка кайттык, йорт тергездек. Минем өчен яңа өйдә әтием бүлмә бүлде, велосипед, чаңгы алып бирде. Бай яшәмәдек, тик күңел байлыгыбыз мул булу мине тулы бәхетле итә иде. Энем белән сеңлем тугач та, минем хакта «ияреп килгән» дигән сүз булмады. Мин белмим, энем белән сеңлем беләме-юкмы икән бу хакта.

Хәзер инде өйләндем. Буш вакыт булуга, хатыным Ландыш белән әти-әни янына кайтабыз. Энем Линзат, сеңлем Элиза йөгереп чыгып каршылыйлар. Мин алар өчен зур абый. Әтием һаман да олы йөрәкле әти булып кала бирә. Без кайтуга, мунчасын яга, шашлыгын куя. Барыбыз бергә түгәрәк өстәл янына җыелышабыз. Әтиемнең кулы да алтын. Машинам төзек булмаса, төзәтешә, киткәндә күчтәнәчсез җибәрми.

Үз әтиемнән күрмәгән барлык ярату хисләрен, эшкә, тормышка өйрәтүне мин Филарис әтиемнән күрдем. Бу язмам белән чиксез рәхмәтемне, үзенеке итеп яздырып, яратып карап үстергән әтиемә зур рәхмәт әйтәсем килә.

Егетләр, авырлыклардан куркып, балаларыгызны ташлап китмәгез! Барыбызга да үрнәк гаилә булып яшәргә язсын! Нишләтсәң дә, ятим күңел түрендә сызлану, сыкрану үзен һәрчак сиздереп тора. Әти-әнисе исән-имин була торып, ятим калмасын иде балалар, таммасын иде аларның күз яше.

Әйе, миңа бәхет елмайган. Бик сирәкләргә генә тия бу бәхет. Үрнәк әти ул минем әтием, мин аның белән горурланам.

Әйнар МӨХӘММӘТДИНОВ,
Актаныш.

КӨЙСЕЗ ЯЗ

яки гиповитаминоз белән ничек көрәшергә?

Яз башында без бераз көйсезгә әйләнәбез: тәнне хәлсезлек, йокы баса, нерв киеренкелеге арта, организм үзенә аерым бер төрле игътибар таләп итә. Табиблар моны тиешле матдәләр җитмәү, ягъни витаминнар кытлыгы белән аңлата. Алар әйтүенчә, мондый халәт гадәттә февральдә үк башлана һәм май ахырына кадәр дәвам итә. Март-апрель – аның иң югары ноктасы. Халык арасында аны авитаминоз дип атыйлар, әмма күпчелегебез моны гиповитаминоз белән бутый. Аларның аермалыклары һәм охшаш яклары нәрсәдә соң? Язгы гиповитаминоз чынлыкта да бармы, әллә аны үзебез уйлап чыгарабызмы? Шул хакта без республиканың клиник иммунология үзәге мөдире, югары категорияле табиб иммунолог-аллерголог Алексей ЛУНЦОВ белән сөйләштек.

КАЙСЫ ОЧРАКТА НИНДИ ВИТАМИН КУЛЛАНЫРГА?

БИЛГЕЛӘРЕ

– Баш авырту һәм йокысызлык
B_3

– Кичке якта күзнең начар күрүе
A

– Чәч коелу, кавыклау
A B_1 B_2 B_3 B_{12} C E

– Тешләр белән проблема, теш казнасы канау
B_1 B_2 C

– Тән тиресенең коры булуы, тәндә күгәргән урыннар күбәю
A C

– Авыз кибү, аппетит булмау
B_1 B_2 B_3 B_6

– Кәефнең еш үзгәрүе
B_6 C

– Сөякләр авырту
D

– Даими хәлсезлек
B_6 B_{12} C E

ЧИШЕЛЕШ ЮЛЛАРЫ

Составында витаминнар һәм микроэлементлар булган ризыклар куллану.

- A – диңгез кәбестәсе, балык бавыры, йомырка сарысы
- B_1 – ярмалар, чикләвекләр, макарон
- B_2 – сөт продуктлары, гөмбә, шпинат, йомырка, сыр
- B_3 – бавыр, кыяклылар, яшелчәләр
- B_6 – йомырка, сөт, сыер ите, кәбестә, кавын
- B_{12} – диңгез продуктлары, бавыр, ит
- C – кара карлыган, цитруслар, гөлҗимеш, борыч
- D – диңгез алабугасы, ак май, йомырка
- E – үсемлек мае, чикләвекләр, сөләйман балыгы

Зөһрә САДЫЙКОВА

